**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 15 гыйнварындагы 28 номерлы карары**

**«2026-2030 елларга Казан шәһәрендә яшьләр сәясәтен үстерү»**
**муниципаль программасын раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы «“Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү” дәүләт программасын раслау турында»гы карарын үтәү йөзеннән, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм бәяләү тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә, шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 3 маендагы 1640 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең 2030 елга кадәр социаль-икътисади үсеш стратегиясен тормышка ашыру буенча чаралар планын раслау турында»гы карарын һәм Казан шәһәре Думасының 2025 елның 17 июнендәге 2-39 номерлы «2030 елга кадәр (перспективада 2040 елга кадәр) Казанның тотрыклы үсеш стратегиясе турында»гы карарын гамәлгә ашыру максатыннан **карар бирәм**:

1. «2026-2030 елларга Казан шәһәрендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын (1 номерлы кушымта) расларга.

2. «Яшьләр сәясәте» тармагы буенча чаралар уздыру өлешендә Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты һәм аның карамагындагы учреждениеләр, шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны әлеге программа кысаларында һәм, тиешле бюджет классификациясен кулланып, чираттагы финанс елына бюджетта исәпкә алына торган акча чикләрендә гамәлгә ашырырга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына (Д.И.Хвостиков):

3.1. квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егерменче көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә

«2026-2030 елларга Казан шәһәрендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру турында мәгълүмат бирергә (2 номерлы кушымта);

3.2. квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егерменче көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлегенә «2026-2030 елларга Казан шәһәрендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасы кысаларында шәһәрнең яшьләр сәясәте учреждениеләре объектларында куркынычсызлыкны һәм аларның террорчылыкка каршы сакланган булуларын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат тапшырырга;

3.3. ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә «2026-2030 елларга Казан шәһәрендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру, шулай ук финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат тапшырырга;

3.4. «2026-2030 елларга Казан шәһәрендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын финанс белән тәэмин итү күләмнәрен үзгәртү буенча тәкъдимнәрне Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә билгеләнгән тәртиптә тапшырырга.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре башлыклары А.И.Салиховка, Р.Х.Шәмсетдиновка, В.В.Жаворонковка, Р.Р.Фәтхетдиновка квартал саен, хисап чорыннан соң килгән айның унбишенче көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына «2026-2030 елларга Казан шәһәрендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру турында хисап тапшырырга (2 номерлы кушымта).

5. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 15 гыйнварындагы
28 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**«2026-2030 елларга Казан шәһәрендә**
**яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасы**

## I. Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа исеме | 2026-2030 елларда Казан шәһәрендә яшьләр сәясәтен үстерү муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Муниципаль заказ бирүче | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты (алга таба – Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты) |
| Программаны төп эшләүче | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты |
| Программаны башкаручы | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы бюджет учреждениеләре, Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты |

| | |
|---|---|
| Программаның максаты | Яшьләрнең һәрьяклап үсеше өчен шартлар тудыру |
| Программаның бурычлары | 1. Яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәренең нәтиҗәле эшчәнлеге һәм сыйфатлы үсеше өчен шартлар тудыру<br>2. Яшьләргә эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү, шулай ук шәһәр тормышында аларның ролен күтәрү өчен шартларны камилләштерү<br>3. Патриотик тәрбия һәм ирекleләр эшчәнлге системасын үстерү һәм камилләштерү.<br>4. Яшьләр сәясәте өлкәсендә нәтиҗәле идарә итү.<br>5. Мәктәп яшендәге балаларны каникул вакытында оештырылган ял белән тәэмин итү |
| Программаны гамәлгә ашыру вакытлары һәм этаплары | 2026-2030 еллар |
| Ярдәмче программалар исемлеге | 1. «Яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәре эшчәнлеген камилләштерү» ярдәмче программасы (3 номерлы кушымта).<br>2. «Балалар һәм яшьләр өчен чаралар оештыру һәм уздыру» ярдәмче программасы (4 номерлы кушымта).<br>3. «Балалар һәм яшьләргә гражданлык-патриотик тәрбия бирү» ярдәмче программасы (5 номерлы кушымта).<br>4. «Яшьләр сәясәте өлкәсендә башка мәсьәләләр» ярдәмче программасы (6 номерлы кушымта).<br>5. «Балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру» ярдәмче программасы (7 номерлы кушымта) |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 5 946 666,5 мең сум тәшкил итә (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты чаралары хисабына – 3 798 981,5 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты чаралары хисабына – 1 785 607,5 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклар чаралары хисабына – 362 077,5 мең |

<table>
<tr>
<td></td>
<td>сум).
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="3">Акча күләме, мең сум</th></tr>
<tr><th>Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты</th><th>Бюджеттан тыш чаралар</th></tr>
<tr><td>2026</td><td>675 266,4</td><td>564 910,2</td><td>72 415,5</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>733 326,5</td><td>593 562,5</td><td>72 415,5</td></tr>
<tr><td>2028</td><td>796 796,2</td><td>627 134,8</td><td>72 415,5</td></tr>
<tr><td>2029</td><td>796 796,2</td><td>җиткерелгәндә</td><td>72 415,5</td></tr>
<tr><td>2030</td><td>796 796,2</td><td>җиткерелгәндә</td><td>72 415,5</td></tr>
<tr><td>БАРЛЫГЫ</td><td>3 798 981,5</td><td>1 785 607,5</td><td>362 077,5</td></tr>
</table>
Иганәчеләр акчасын җәлеп итү мөмкин.<br>Искәрмә: Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында бирелә һәм аңа, тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проектын формалаштырганда, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td>
</tr>
<tr>
<td>Программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td>
<td>Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру 2030 елда түбәндәге нәтиҗәләргә һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- яшүсмерләр клубларында шөгыльләнүче балалар санын 24 000 кешегә җиткерү;<br>- Казан шәһәренең «“Доверие” балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет яшьләр сәясәте учреждениесе белгечләре тарафыннан халыкка шәхси ярдәм күрсәтүне база дәрәҗәдә саклау – ел саен 18 960 кеше;<br>- янгынга каршы куркынычсызлыкны арттыру һәм килүчеләр өчен шартларны яхшырту чаралары булдырылган яшьләр сәясәте объектлары өлешен гомуми саннан 100 процент дәрәҗәсендә саклау;<br>- штат расписаниесе буенча хезмәткәрләрнең гомуми саныннан квалификация күтәрү курсларын үткән хезмәткәрләр өлешен ел саен 9,5% дәрәҗәсендә саклау;</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | - «“Яшүсмер” яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары берләшмәсе» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесенең яшәү урыны буенча яшүсмерләр клублары санын 77 объектка кадәр арттыру (база елы белән чагыштырганда 5 объектка арттыру);<br>- уздырылган гомумшәһәр һәм конкурс чаралары санын база чорыннан 5 берәмлеккә арттыру;<br>- талантлы һәм инициативалы яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар санын база чоры дәрәҗәсендә саклау, 212 кеше;<br>- Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты ярдәмендә яшьләр оешмаларының гамәлгә ашырылган проектлары санын база чорыннан 10 берәмлеккә арттыру;<br>- патриотик юнәлештәге чаралар санын база елы дәрәҗәсендә саклау, 27 чара;<br>- йөкләмәләрне билгеләнгән контроль вакыт аралыгында үтәүне 100 процентка тәэмин итү;<br>- яшьләр сәясәте учреждениеләрендә хезмәт хакы фондының расланган күләменнән арттыру очрагы булмау, 0 берәмлек;<br>- ведомство карамагындагы учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләрдән алынган керем күләмнәренең план күрсәткечләрен 100 процентка үтәү;<br>- балалар һәм яшьләрне оештырылган ял формалары белән тәэмин итүне 50 000 кешегә кадәр арттыру |

## II. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, шул исәптән Программа белән хәл итү каралган мәсьәләләр

Программа гамәлдәге Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, Казан шәһәре норматив-хокукый актлары нигезендә эшләнде һәм балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыруга, балалар һәм яшьләрне тәрбияләү, үстерү, социаль яктан формалаштыру, аларга психологик ярдәм итү, үзләрен күрсәтү өчен шартлар

булдыруга һәм тәэмин итүгә, яшьләр сәясәте учреждениеләренең җәлеп итүчәнлеген арттыруга юнәлдерелгән.

Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты Казан шәһәрендә яшьләр сәясәтен формалаштыру һәм гамәлгә ашыруның төп координаторы булып тора. Аның төп эш юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

- яшьләр сәясәте инфраструктурасын үстерү;
- яшьләргә социаль-психологик ярдәм күрсәтү;
- яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү;
- яшьләр арасында ирекләләр эшчәнлеген үстерү;
- балалар һәм яшүсмерләрнең девиант тотышларын профилактикалау;
- студентларның үзешчән иҗатын һәм яшь талантларны үстерү;
- талантлы яшьләрне, яшьләр инициативаларын ачыклау һәм аларга ярдәм итү;
- яшүсмерләр һәм яшьләрнең күңел ачу чараларын һәм ялларын оештыру.

Әлеге юнәлешләрне гамәлгә ашыру өчен Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты күбесе уникаль булып торган проектларны гамәлгә ашыра. Мондый проектлар һәм чаралар саны, шулай ук аларда катнашучы яшьләр саны ел саен арта бара.

Үз эшчәнлегендә Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты үз карамагындагы учреждениеләргә, югары уку йортларына, һөнәри белем бирү оешмаларына һәм яшьләр оешмаларына таяна.

Шәһәр яшьләр инфраструктурасы Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы биш учреждениедән тора: 72 яшүсмерләр клубын берләштерә торган Казан шәһәренең «“Яшүсмер” яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары берләшмәсе» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе; 12 муниципаль лагерьны берләштерә торган Казан шәһәренең «“Ял” балаларны сәламәтләндерү, ял иттерү, эш белән тәэмин итү шәһәр үзәге” яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе; «“Доверие” балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе; Казан шәһәренең «А.Гайдар исемендәге Казан яшьләр үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе; Казан шәһәренең «“Дуслык” девиант тәртипле балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль-тернәкләндерү үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе. Бер яктан – ул балалар һәм яшьләргә хезмәт күрсәтүнең киң спектры булган җитди оештыру потенциалы (30 меңнән артык кеше), икенче яктан – бу карап тоту һәм үстерү өчен ресурслар таләп итә торган зур комплекс.

Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты үз эшчәнлегендә шәһәрнең потенциалын формалаштыруда иң элек яшь буынга мәдәни, әхлакый кыйммәтләр сеңдерү, гражданлык позициясе тәрбияләү, күпкырлы интеллектуаль үсеш өчен шартлар тудыру юлы белән мөһим юнәлешләрнең зур спектрын тормышка ашыра.

Сәләтле яшьләр белән эшләү фундаменталь һәм гамәли фәннән алып иҗатка кадәр, патриотик тәрбиядән алып иреклеләр эшчәнлегенә кадәр, җанатарлар культурасыннан алып спортның яңа төрләрен үстерүгә кадәр булган төрле өлкәләрне үз эченә ала.

Казан, Россиянең күп кенә төбәкләре белән чагыштырганда, тиз темпта үсә һәм, нәтиҗәдә, ил һәм дөнья яшьләрен белем алу, һәрьяклап шәхси һәм һөнәри үсеш өчен җәлеп итә торган үзәкләрнең берсенә әверелә. Шул ук вакытта яшьләргә ярдәм итүнең барлык формаларын актуальләштерү һәм системалаштыру таләп ителә.

Казан яшьләренә белем алу өчен киң мөмкинлекләр булдырылган: шәһәрнең мәгариф учреждениеләрендә укудан алып Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты гамәлгә ашыра торган чараларда һәм проектларда катнашуга кадәр. Ел саен волонтерлар, иҗади актив лидерлары өчен профильле сменалар циклы оештырыла. Нәтиҗә буларак, яшь активистлар командасы формалаша, алар яшьләр инициативаларын алга җибәрә, социаль проектларны эшкәртә һәм бөтенроссия һәм халыкара конкурсларда, иҗади фестивальләрдә һәм телевизион проектларда уңышлы катнаша («Студентлар язы», «Беренче курс студентлары көне», «Язгы тамчы», «Ягымлы яз», «Созвездие – Йолдызлык» һәм башкалар).

Яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең югары гражданлык активлыгына патриотик эшне оештыру: истәлекле даталар хөрмәтенә митинглар, ветераннар, батырлар һәм иң яхшы тарихчы-белгечләр катнашында семинарлар һәм конференцияләр уздыру, эзләнүчеләр хәрәкәтенә булышу ярдәм итә.

Яшьләр арасында иреклеләр эшчәнлеге гражданлык җаваплылыгын, социаль активлыкны һәм шәхес үсешен үстерүнең мөһим юнәлеше булып тора. Әлеге эшчәнлек яшьләрдә җәмгыять эшчәнлегендә катнашу хисен формалаштыруга, команда күнекмәләрен, лидерлык сыйфатларын һәм социаль проблемаларны хәл итә белүне үстерүгә ярдәм итә. Иреклеләр эшчәнлегенә Казан шәһәренең Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты каршындагы Иреклеләр үзәген оештыру ярдәм итә. Әлеге үзәкнең эше өч төп юнәлеш буенча алып барыла: вакыйгага бәйле волонтерлык, махсус хәрби операциягә ярдәм, эковолонтерлык.

Хәзерге яшьләр Интернеттан даими файдалана, аны төп мәгълүмат чыганагы һәм төп аралашу чарасы буларак карый. Шуңа бәйле рәвештә социаль челтәрләрдә эш активлаша, материаллар бирү ысуллары һәм формалары үзгәрә (эчтәлекле кыска контент урнаштыру һәм чараны фактта уздыруга кадәр интерактив җәлеп итү). Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты вакыйгаларны анонслау, яшьләр белән аралашу, аларны актив иҗтимагый тормышка тарту өчен социаль челтәрләрдә коммуникацияләр төзи.

Яшь буынга мәдәни, әхлакый кыйммәтләр сеңдерү, гражданлык позициясе тәрбияләү, иреклеләр эшчәнлеген үстерү, күпкырлы интеллектуаль үсеш өчен шартлар тудыру исәбенә шәһәр халкының шәхси потенциалын формалаштыру буенча мөһим юнәлешләр эшләнә. Бу очракта программа яшьләрне камилләштерү, тәрбияләү һәм үз-үзен тормышка ашыру зарурлыгына бәйле проблемаларны хәл итүгә нәтиҗәле ярдәм итәчәк.

Шулай итеп, Казанда яшьләр сәясәте, шәһәрдәге социаль сәясәтнең өстенлекле юнәлешләренең берсенә әйләнеп, бүген системалы һәм тотрыклы булып тора, яшь буын үсешенә һәм аның проблемаларын хәл итүгә актив ярдәм итә.

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары, тышкы һәм эчке икътисади һәм сәяси факторлар хәзерге вакытта һәм якын киләчәктәге 10-15 елга яшьләр сәясәтен үстерү өчен фактта өстенлекләрне билгели торган һәм яшьләрне формалаштыру һәм тәрбияләү өчен сыйфат ягыннан башка мохит тудыручы социаль мәсьәләләргә игътибар бирергә мәҗбүр итә.

1. Демографик үсештә тискәре тенденцияләрнең көчәюе. Якындагы ун ел эчендә Россиянең барлык төбәкләрендә халыкның шактый картаюы күзәтелә, эшкә яраклы яшьтән өлкәнрәк халык саны артачак. Халык санының кимүе нигездә яшьләр, 20-40 яшьлек гражданнар категориясенә бәйле булачак. Демографик процесслар нәтиҗәсендә яшьләр санының кимүе Россия Федерациясенең барлык субъектларына кагылачак, ләкин ул бертөрле булмаячак. “Яшьләр” социаль-демографик төркемен 14-17 яшьлек мәктәп укучылары һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары студентлары – 56 меңнән артык кеше тәшкил итә; 18-24 яшьлек яшьләр (аларның күпчелеге студентлар) – 165 мең кеше; 25-35 яшьлек яшьләр – эшләүче яшьләр, яшь гаиләләр – 193 меңнән артык кеше.

2. Яшүсмерләр һәм яшьләр арасында психологик халәт, яшьләрнең деструктив тәртибенә бәйле хокук бозулар һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр куркынычы арту. Күп кенә эчке һәм тышкы факторларның тискәре йогынтысы

үсү җәмгыятьтә социаль киеренкелек үсеше куркынычын арттыра. Яшь буынга әле тәртипкә салынмаган кыйммәтләр системасы, дөньяга караш формалашуның тотрыклы булмавы, барлык мәгълүмати җәмгыять өчен хас булган социаль мөнәсәбәтләрнең тотрыксызлыгы, күрсәтелә торган үз-үзеңне тоту үрнәкләрен тәнкыйтьсез кабул итү, югары агрессивлык хас. Деструктив тәртипнең барлык формаларына каршы тору өчен нигез булып формалашкан тотрыклы рухи-әхлакый кыйммәтләр тора.

Яшьләр арасында хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләсе актуаль булып тора, яшьләр арасында җинаятьчелек мөһим күренеш булып кала бирә. Яшьләр тарафыннан кылынган хокук бозулар динамикасы гомуми җинаятьчелек динамикасына охшаш, закон бозучыларның гомуми саныннан 14-29 яшьлек яшьләр тарафыннан кылынган хокук бозулар саны якынча 28 процент тәшкил итә, шул ук вакытта аларның 50 проценты диярлек 18-24 яшь төркеменә туры килә. Хокук бозу очракларында балигъ булмаганнар да, яшьләр дә еш катнаша, алар арасында иң күп санда мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен кулланып яисә компьютер мәгълүматы өлкәсендә (“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен һәм мобиль элемтә чараларын кулланып) милеккә каршы, наркотик һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә бәйле җинаятьләр бар. Шул ук вакытта яшьләр арасында халыкның сәламәтлегенә һәм җәмгыятьтә әхлакка каршы җинаятьләр кими бара.

Борчулы халәттә булган яшьләр саны арта баруын еллык статистика – ышаныч телефоннары буенча мөрәҗәгать итү очраклары артуы һәм психологик-педагогик ярдәмгә ихтыяҗ зур булу күрсәтә. Гомумән, мондый динамика хәзерге вакытта яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең психологик ярдәмне уңай кабул итүләрен, аларның өлкәннәргә һәм карарлар кабул итү институтларына ышанычын ныгыту өчен теләсә нинди мөмкинлекләрдән файдаланырга кирәклеген күрсәтә.

3. Яшьләрнең мәшгульлеге һәм эшкә урнашуы. Яшьләрне эшкә урнаштыру мәсьәләсе яшьләрне үстерүдә бер авырлык булып тора. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең өстенлекле сәнәгать тармаклары предприятиеләрен, өстенлекле территорияләрне һәм агломерацияләрне квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен системалы чаралар эшләү максатыннан яшь белгечләрне, өстенлекле тармакларның һәм белгечлекләрнең яшь галимнәрен җәлеп итү, аларны шушы урынга беркетү механизмнарын эшләү, уңайлы яшәү һәм үзләрен күрсәтү өчен шартлар тудыру мөһим.

4. Яшь гаиләләрнең проблемалары. Вазгыятьне анализлау яшь гаилә институтына дәүләт ярдәме кирәклеген раслый. Сүз, барыннан да элек, гаилә яшәеше өчен уңайлы пространство һәм аның мәнфәгатьләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыру турында бара. Дөньяга тотрыклы караш һәм кыйммәтләргә, шул исәптән нык һәм имин гаиләгә, җаваплы ата-ана булуга һәм гаилә тормышы кыйммәтләренә тартылу 20-25 яшьтә формалаша. Яшь гаиләләр өчен проблемаларның ике блогы аеруча актуаль. Беренчесе – яшь ир белән хатынның матди яктан тәэмин ителеше, торак һәм эшкә урнашу проблемаларын үз эченә алган социаль-икътисади блок. Үз торагыңны сатып алу – гаилә корганда, бала планлаштырганда һәм бала туганда иң төп мәсьәләләрнең берсе. Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендә бушлай субсидияләр, процентсыз бүлеп түләү форматында торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фондының социаль ипотека системасында ташламалы ипотека программалары эшләп килә. Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә республика һәм федераль бюджет акчаларыннан уртак финанслау шартларында яшь гаиләләргә торак бәясенең 30-35 проценты күләмендә кире кайтарылмый торган субсидияләр бирү форматында үз торакларын сатып алуда дәүләт ярдәме күрсәтү муниципаль программасы эшли. Бүгенге көнгә программалар гамәлдә булган чорда Казанның 5 меңнән артык яшь гаиләсенә торак проблемаларын хәл итүдә дәүләт ярдәме күрсәтелгән. Хәзерге яшь гаиләләрне тикшерүләр гаилә тәрбиясе проблемаларына, яшь гаиләнең тотрыклылыгы мәсьәләләренә һәм куркыныч янаган төркемгә караган гаиләләр белән эшләүгә ныклы игътибар бирү, яшьләргә, шул исәптән яшь гаиләләргә психологик яктан булышу, даими ярдәм итү кирәклеген күрсәтә.

5. Яшь буынны заманча тәрбияләү үзенчәлекләре, гражданлык патриотизмын формалаштыру. Хәзерге шартларда тәрбия иҗади, интеллектуаль, рухи, әхлакый һәм физик яктан үскән, үз эшчәнлеге нәтиҗәләре өчен җаваплы шәхес формалаштыруда хәлиткеч роль уйный, ә патриотик тәрбиянең көчәюе эчке һәм тышкы таләпләргә җавап булып тора. Яңа иҗтимагый тенденцияләр нигезендә яшь кешене шәхес итеп тәрбияләүнең заманча системасын формалаштыру өчен аның үсеше өчен шартлар тудыру һәм яшьләрне социальләштерүнең барлык субъектларының үзара нәтиҗәле хезмәттәшлеген оештыру буенча актуаль мәсьәләләрне хәл итү мөһим. Заманча социологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, кыйммәтләргә тартылу сизелерлек үзгәреш кичерә, хәзерге балалар һәм яшьләр күбрәк индивидуаль үзенчәлекләрне, сайлау ирекен, традицияләрдән азат ителүне сайлыйлар, шул

исәптән яшьләрнең социаль-икътисади мобильлеге арту нәтиҗәсендә, ул, барлык инновацион үзләштерүнең зур потенциалына ия булып, бүген үз күнекмәләрен һәм талантларын үстерү өчен күбрәк мөмкинлекләр бирә һәм социаль каршылыкларны тизрәк узарга ярдәм итә. Казан шәһәре, Татарстан Республикасы яшьләргә патриотик тәрбия бирү һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү (ел саен патриотик юнәлештәге чаралар белән 200 меңгә якын кеше тәэмин ителә, шәһәрнең 30 мәгариф учреждениесендә 20 хәрби-патриотик клуб эшли), ирекледәр хәрәкәте (Казан шәһәренең волонтерлык берлегенә 60 меңнән артык волонтер һәм 100 дән артык ирекледәр берләшмәсе кертелгән) буенча Россия Федерациясендә алдынгылар рәтендә булуга карамастан, гражданлык патриотизмын үстерү мәсьәләләрендә җәмгыятьнең җитәрлек дәрәҗәдә катнашмавы күзәтелә; җәмгыять тормышында катнашуның мөһимлеген аңламау балалар һәм яшьләрнең генә түгел, өлкәннәрнең, аларның ата-аналарының да гражданлык һәм патриотик мәсьәләләр, рухи әхлакый кыйммәтләр белән аз кызыксынуына китерә; буыннар арасында үзара бәйләнеш булмау һәм кыйммәтләрне буыннан-буынга тапшырмау, мохит һәм медианың тискәре йогынтысы еш кына гражданлык-патриотик үсешкә һәм рухи-әхлакый нигезләргә каршы килә торган тискәре кыйммәтләр һәм идеяләр таралуына китерә.

## III. Гамәлгә ашыру вакытын күрсәтеп, Программаның максатлары һәм бурычлары, чаралар исемлеге һәм алар турында кыскача мәгълүмат

Программаның максаты – яшьләрне һәрьяклап үстерү өчен шартлар булдыру.

Куйган максатка ирешү өчен системалы характердагы түбәндәге бурычларны хәл итү таләп ителә:

1) яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәренең нәтиҗәле эшчәнлеге һәм сыйфатлы үсеше өчен шартлар тудыру;

2) яшьләргә эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү, шулай ук шәһәр тормышында аларның ролен күтәрү өчен шартларны камилләштерү;

3) патриотик тәрбия һәм ирекледәр эшчәнлеге системасын үстерү һәм камилләштерү;

4) яшьләр сәясәте өлкәсендә нәтиҗәле идарә итү;

5) мәктәп яшендәге балаларны каникул вакытында оештырылган ял белән тәэмин итү.

Программа үзенчәлекле бурычлары тиешле ярдәмче программаларда чагылдырылган программа чараларын гамәлгә ашыруның муниципаль дәрәҗәсен күздә тота.

«Яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәре эшчәнлеген камилләштерү» ярдәмче программасы (1 нче ярдәмче программа) яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәренең нәтиҗәле эшләве һәм сыйфатлы үсеше өчен шартлар тудыруга, балалар һәм яшүсмерләр белән эшләүнең инновацион формаларын куллануга юнәлдерелгән.

«Балалар һәм яшьләр өчен чаралар оештыру һәм үткәрү» ярдәмче программасы (2 нче ярдәмче программа) яшьләр арасында тискәре (җәмгыять өчен куркыныч тудыра торган) күренешләрне киметүгә, шәһәр балаларының һәм яшьләренең социаль, мәдәни, рухи, физик тәрбия һәм үсеш дәрәҗәсен арттыруга, сәләтле яшьләр вәкилләрен алга таба аларның иҗади үсешенә булышу максатыннан ачыклауга һәм шәһәрнең зур массакүләм чараларын югары сәнгать дәрәҗәсендә уздыруга юнәлдерелгән.

«Балалар һәм яшьләргә гражданлык-патриотик тәрбия бирү» ярдәмче программасы (алга таба – 3 нче ярдәмче программа) биш юнәлештә гамәлгә ашырыла: югары һәм һөнәри уку йортлары белән эшләү; карамактагы учреждениеләрдә эшләү; патриотик яшьләр берләшмәләре белән эшләү; башка профильле яшьләр оешмалары белән эшләү; Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының традицион планлы патриотик чараларын үткәрү.

Яшьләр белән эшләүнең төрле юнәлешләре, формалары һәм алымнары: хәрби-спорт уеннары үткәрү, Бөек Ватан сугышы һәм локаль низаглар ветераннары белән очрашулар, сафта йөрү һәм җырлау смотр-конкурслары һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары өчен ел саен үткәрелә торган актив мәктәпләре, хәзерге заман батыры образын формалаштыруга юнәлтелгән тренинг чаралары уздыру.

«Яшьләр сәясәте өлкәсендә башка мәсьәләләр» ярдәмче программасы (4 нче ярдәмче программа) тармак белән идарә итүнең нәтиҗәле системасын формалаштыруга һәм яшьләр сәясәте учреждениеләреннән файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

«Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру» ярдәмче программасы (алга таба – 5 нче ярдәмче программа) Казан шәһәренең балаларының ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру өчен тиешле шартлар тудыруга, каникул вакытында аларның мәшгульлеген тәэмин итүгә, сәламәтләндерү нәтиҗәсен арттыруга юнәлдерелгән.

Программаның максатлары һәм бурычлары киселешендә нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары исемлеге Программаның 1 номерлы кушымтасында китерелгән.

Программаны гамәлгә ашыру вакыты: 2026-2030 еллар.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны гамәлгә ашыруны финанс яктан тәэмин итү 3 798 981,5 мең сум күләмендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты чараларын, 1 785 607,5 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты чараларын һәм 362 077,5 мең сум күләмендә бюджеттан тыш чыганакларны куллануны күздә тота. Программаны финанслауның гомуми күләме 5 946 666,5 мең сум тәшкил итә.

Яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләренең бюджеттан тыш акчаларының төп чыганаклары булып түләүле хезмәтләр тора, аларның күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана, ә исемлек Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 24 маендагы 3274 номерлы «Казан шәһәре бюджетыннан ассигнованиеләр алучы муниципаль учреждениеләрнең түләүле хезмәтләре турында»гы карары белән җайга салына.

Бюджеттан тыш акчалар Татарстан Республикасы Казначылык департаментының территориаль органында эшмәкәрлек эшчәнлегеннән алынган, эшмәкәрлек һәм керем китерә торган башка эшчәнлектән акчалар күчерү һәм тоту өчен каралган акчаларны исәпкә алу буенча казначылык счетларын ачуга рөхсәт нигезендә ачылган яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләренең шәхси счетларына күчерү юлы белән керә.

Яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләренең бюджеттан тыш акчаларын тотуны контрольдә тотучы органнар булып Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты һәм Татарстан Республикасы Казначылык департаментының территориаль органы тора. Бюджеттан тыш акчаларны куллану турында хисап «Барс.Web-Своды» программа комплексында түбәндәге формалар буенча формалаштырыла:

- 0503155а – «Бюджет учреждениеләрендә, автоном учреждениеләрдә һәм башка оешмаларда кассага акча керүе һәм акчаларның чыгуы турында хисап»;
- 19 – «Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән кергән керемнәр буенча мәгълүматлар».

Юридик һәм физик затлардан иганәчелек яки хәйриячелек ярдәме рәвешендә финанс ярдәме кергән очракта, акчалар «Грантлар, премияләр, ирекле иганәләр» счетында җыела һәм 0503155а формасындагы хисапларда күрсәтелә.

Программаны гамәлгә ашырыла торган ярдәмче программалар киселешендә финанслар белән тәэмин итү Программага 2 номерлы кушымтада китерелә.

Программаны гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү фаразлау характерында һәм аңа, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## V. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны гамәлгә ашыруда Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының барлык структуралары, аның карамагындагы учреждениеләр, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре һәм эшчәнлекнең беркетелгән юнәлешләре буенча иҗтимагый яшьләр оешмалары катнаша. Муниципаль милектә булмаган оешмаларны башкаручылар сыйфатында җәлеп итү килешү буенча гамәлгә ашырыла.

Программа чараларын гамәлгә ашыру барышында муниципаль заказчы төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә, чараларны гамәлгә ашыру барышын һәм турыдан-туры башкаручыларның акчалардан нәтиҗәле файдалануын контрольдә тота. Программа чараларын гамәлгә ашыру Программа заказчысы тарафыннан Программа чараларын башкаручыларның барысы белән төзелә торган муниципаль контрактлар нигезендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына төгәл туры китереп, шулай ук муниципаль учреждениеләр өчен билгеләнә торган муниципаль биремнәр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Программа муниципаль заказчысы:

- квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның егермесенә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә программаны тормышка ашыру турында билгеләнгән форма буенча мәгълүмат тапшыра;

- квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егермесенә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлегенә

Программа кысаларында шәһәрнең яшьләр сәясәте учреждениеләре объектларында куркынычсызлыкны һәм аларның террорчылыкка каршы сакланган булуларын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат тапшыра;

- ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Программаны гамәлгә ашыру, шулай ук финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат тапшыра;

- Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә билгеләнгән тәртиптә Программаның финанс яктан тәэмин итү күләмнәрен үзгәртү буенча тәкъдимнәрне тапшыра;

- хисап елыннан соң килә торган елның 1 июненнән дә соңга калмыйча, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында Программаны гамәлгә ашыру турында еллык хисап урнаштыра.

Программаны бергә башкаручылар (Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре) квартал саен, хисап чорыннан соңгы айның унынчы көненә кадәр, Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына Программаны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат тәкъдим итәләр.

## VI. Программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаның социаль-икътисади нәтиҗәсенә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру механизмын камилләштерү һәм үстерү – шәһәрдә яшь гражданнарның үз тормыш юлын сайлау, дәүләт һәм иҗтимагый үсеш мәнфәгатьләрендә яшьләрнең инновацион потенциалын гамәлгә ашыру өчен социаль һәм оештыру шартлары тудыру, шулай ук яшьләрнең социаль, мәдәни, рухи һәм физик үсешенә ярдәм итү хисабына ирешеләчәк.

Кичектерелгән гамәл эффекты түбәндәгечә чагылачак:

- яшьләр арасында җинаятьчелек, наркомания, алкоголизм, экстремизм кебек тискәре (иҗтимагый куркыныч) күренешләрне киметүдә;

- яшьләрне Казан шәһәренең социаль-икътисади, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни үсеше процессларына кертүнең нәтиҗәле механизмнары барлыкка килүдә;

- яшьләрнең ялы һәм иҗаты өлкәсендә нәтиҗәле эш оештыруда;

- яшьләр белән эшләү белән шөгыльләнүче оешмалар эшчәнлеген координацияләүдә;

- яшьләр сәясәте өлкәсендә хезмәтләрнең сыйфатын һәм төрлелеген арттыруда;

- киләчәктә иҗади үсешенә ярдәм итү максатыннан сәләтле яшьләрне ачыклауда;

- зур шәһәр массакүләм чараларын югары сәнгать-иҗат дәрәҗәсендә уздыруда.

Муниципаль программага
1 номерлы кушымта

**«2026-2030 елларга Казан шәһәрендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары**

| Максат | Бурыч | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторы, үлчәү берәмлеге | Индикатор күрсәткечләре | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2025 ел (база елы) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Яшьләрнең һәрьяклап үсеше өчен шартлар тудыру | 1. Яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәренең нәтиҗәле эшчәнлеге һәм сыйфатлы үсеше өчен шартлар тудыру | Бюджет һәм бюджеттан тыш акчалар хисабына «Доверие» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе белгечләренең индивидуаль чараларында катнашкан кешеләр саны, кеше | 18 960 | 18 960 | 18 960 | 18 960 | 18 960 | 18 960 |
| | | Бюджет акчалары хисабына яшүсмерләр клубларында түгәрәкләр | 600 | 600 | 610 | 610 | 620 | 620 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | саны, берәмлек | | | | | | |
| | | Яшүсмерләр клубларында бюджеттан тыш акчалар хисабына түгәрәкләр саны, берәмлек | 230 | 230 | 240 | 240 | 250 | 250 |
| | | Яшүсмерләр клубларында шөгыльләнүче балалар саны, кеше | 23 000 | 23 000 | 23 500 | 23 500 | 24 000 | 24 000 |
| | | Бюджет һәм бюджеттан тыш акчалар хисабына «А.Гайдар исемендәге Казан яшьләр үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесендә шөгыльләнүче балалар саны, кеше | 1 100 | 1 100 | 1 100 | 1 100 | 1 100 | 1 100 |
| | | Авыр тормыш хәлендә калган балаларның вакытлыча яшәвен оештыру, койка урыны | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | саны | | | | | | |
| | 2. Яшьләргә эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү, шулай ук шәһәр тормышында аларның ролен күтәрү өчен шартларны камилләштерү | Үткәрелгән бәйрәм чаралары саны, берәмлек | 54 | 55 | 56 | 57 | 58 | 59 |
| | | Үткәрелгән чаралар саны (талантлы яшьләргә ярдәм итү буенча), берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 |
| | 3. Патриотик тәрбия бирү системасын үстерү һәм камилләштерү | Патриотик юнәлештә уздырылган чаралар саны, берәмлек | 27 | 27 | 27 | 27 | 27 | 27 |
| | | Актив яшьләргә һәм патриотик юнәлештәге яшьләр оешмаларына ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар саны, берәмлек | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 |
| | 4. Яшьләр сәясәте өлкәсендә нәтиҗәле идарә итү | Ведомство карамагындагы учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | торган түләүле хезмәтләрдән алынган керем күләмнәренең план күрсәткечләрен үтәү, % | | | | | | |
| | | Хезмәт өчен түләүнең расланган фондын арттыру очраклары ачыкланган учреждениеләр саны, берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | | Билгеләнгән контроль вакыт аралыгында башкарылган йөкләмәләр өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| | 5. Мәктәп яшендәге балаларны каникул вакытында оештырылган ял белән тәэмин итү | Балаларны һәм яшьләрне оешкан ял итү формалары белән тәэмин итү, кеше | 48 158 | 48 530 | 48 900 | 49 260 | 49 630 | 50 000 |

Муниципаль программага
2 номерлы кушымта

**«2026 - 2030 елларга Казан шәһәрендә яшьләр сәясәтен үстерү»**
**муниципаль программасын гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү**

| № т/б | Бурыч | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме (мең сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| 1 | «Яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәре эшчәнлеген камилләштерү» | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 591 402,0 | 645 850,1 | 705 644,7 | 705 644,7 | 705 644,7 |
| | | Бюджеттан тыш чаралар | 47 100,0 | 47 100,0 | 47 100,0 | 47 100,0 | 47 100,0 |
| 2 | «Балалар һәм яшьләр өчен чаралар оештыру һәм үткәрү» | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты (Казан шәһәре районнарында чаралар үткәрүне финанслауны исәпкә алып) | 10 983,1 | 10 983,1 | 10 983,1 | 10 983,1 | 10 983,1 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | «Балаларга һәм яшьләргә гражданлык-патриотик тәрбия бирү» | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 960,0 | 960,0 | 960,0 | 960,0 | 960,0 |
| 4 | «Яшьләр сәясәте өлкәсендә башка мәсьәләләр» | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 15 252,1 | 15 296,6 | 15 332,9 | 15 332,9 | 15 332,9 |
| 5 | «Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру» | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 56 669,2 | 60 236,7 | 63 875,5 | 63 875,5 | 63 875,5 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 564 910,2 | 593 562,5 | 627 134,8 | җиткерелгәндә | җиткерелгәндә |
| | | Бюджеттан тыш чаралар | 25 315,5 | 25 315,5 | 25 315,5 | 25 315,5 | 25 315,5 |
| **Программа буенча барлыгы, шул исәптән** | | | **1 312 592,1** | **1 399 304,5** | **1 496 346,5** | **869 211,7** | **869 211,7** |
| **– Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты** | | | **675 266,4** | **733 326,5** | **796 796,2** | **796 796,2** | **796 796,2** |
| **– Татарстан Республикасы бюджеты** | | | **564 910,2** | **593 562,5** | **627 134,8** | җиткерелгәндә | җиткерелгәндә |
| **- бюджеттан тыш акчалар** | | | **72 415,5** | **72 415,5** | **72 415,5** | **72 415,5** | **72 415,5** |

Муниципаль программага
3 номерлы кушымта

**1 нче «Яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәре эшчәнлеген камилләштерү» ярдәмче программасы**

## I. Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның атамасы | Яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәре эшчәнлеген камилләштерү (алга таба – 1 нче ярдәмче программа) |
| Муниципаль заказ бирүче | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты (алга таба – Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты) |
| 1 нче ярдәмче программаны төп эшләүче | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты |
| 1 нче ярдәмче программаны төп башкаручылар | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына караган бюджет учреждениеләре |
| 1 нче ярдәмче программаның максаты | Яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәренең нәтиҗәле эшчәнлеге һәм сыйфатлы үсеше өчен шартлар тудыру |
| 1 нче ярдәмче программа бурычлары | 1. Социальләштерү барышында балалар һәм яшүсмерләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча сыйфатлы хезмәтләр күрсәтү өчен шартлар тудыру, сәләтле балаларга, фән олимпиадаларында, иҗади конкурсларда җиңүчеләргә ярдәм итү, үсеп килүче буынның тормышта үзен табуы өчен мөмкинлекләр тудыру.<br>2. Яшьләр сәясәте учреждениеләрен аларның эш нәтиҗәлелеген, шулай ук алар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең төрлелеген һәм сыйфатын арттыруны тәэмин итү максатыннан модернизацияләү |
| 1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру | 2026-2030 еллар |

<table>
<tr><td>вакытлары</td><td></td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td><td>1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 3 589 686,2 мең сум тәшкил итә (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына – 3 354 186,2 мең сум, бюджеттан тыш чаралар хисабына – 235 500,0 мең сум.<br><table><tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="2">Акча күләме, мең сум</th></tr><tr><th>Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты</th><th>Бюджеттан тыш чаралар</th></tr><tr><td>2026</td><td>591 402,0</td><td>47 100,0</td></tr><tr><td>2027</td><td>645 850,1</td><td>47 100,0</td></tr><tr><td>2028</td><td>705 644,7</td><td>47 100,0</td></tr><tr><td>2029</td><td>705 644,7</td><td>47 100,0</td></tr><tr><td>2030</td><td>705 644,7</td><td>47 100,0</td></tr><tr><td>БАРЛЫГЫ</td><td>3 354 186,2</td><td>235 500,0</td></tr></table><br>Искәрмә: 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында, аңа, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>1 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм<br>1 нче ярдәмче программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td><td>1 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру 2030 елда түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- яшүсмерләр клубларында шөгыльләнүче балалар санын 24000 кешегә кадәр җиткерү;<br>- Казан шәһәренең «Доверие» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет яшьләр сәясәте учреждениесе белгечләре тарафыннан халыкка шәхси ярдәм күрсәтүне база дәрәҗәдә саклау – ел саен 18 960 кеше;<br>- «“Яшүсмер” яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары берләшмәсе» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесенең яшәү урыны буенча яшүсмерләр клублары санын 77 объектка кадәр арттыру (база елы белән чагыштырганда 5 объектка арттыру);<br>- штат расписаниесе буенча хезмәткәрләрнең гомуми саныннан квалификация күтәрү курсларын үткән хезмәткәрләр өлешен ел саен 9,5% дәрәҗәсендә саклау;</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | - янгынга каршы куркынычсызлыкны арттыру һәм кешеләрнең яшәү шартларын яхшырту чаралары булдырылган яшьләр сәясәте объектлары санын гомуми саннан 100 процентка кадәр арттыру;<br>- яшьләр сәясәте учреждениеләре тарафыннан энергия ресурсларын куллануны база елы белән чагыштырганда 5 процентка киметү |

## II. 1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, шул исәптән 1 нче ярдәмче программа ярдәмендә хәл ителә торган проблемалар

Үз эшчәнлегендә Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы учреждениеләргә, югары уку йортларына, һөнәри белем бирү оешмаларына һәм яшьләр оешмаларына таяна.

Балалар һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру җәмгыятьнең даими үсә торган төркеме белән эшләүдән гыйбарәт. Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә эшнең үзенчәлеге коммуникацияләрнең универсаль алгоритмнары булмаудан гыйбарәт, чөнки балалар һәм яшьләрнең һәр яшь төркеменә үз үзенчәлекләре һәм үз теле хас. Балалар һәм яшүсмерләр Казан шәһәрендәге яшьләр сәясәтенең мөһим объекты булып тора. Һәм алар белән эшләүдә беренче урынны яшәү урыны буенча яшүсмерләр клублары алып тора. Казан – Россиядә мондый эш формасын саклап кала алган аз санлы шәһәрләрнең берсе. Бүген ул бик кирәк, чөнки яшәү урыны буенча ишегалларында балаларны эш белән тәэмин итү буенча зур социаль бурычны хәл итә, урамдагы тискәре күренешләрнең, шул исәптән наркомания һәм криминал кебек күренешләрне профилактикалау факторы булып тора. Клубларга сәламәтлек һәм иҗади сәләтләре буенча җитди чикләүләре булмаган барлык яшүсмерләр дә йөри алуы принципиаль әһәмияткә ия, ә башка учреждениеләрдә тиешле сайлап алу уздырыла.

Казан шәһәренең «Яшүсмер» муниципаль бюджет яшьләр сәясәте учреждениесе – Россиядә яшәү урыны буенча яшүсмерләр клубларының иң эре челтәре: 70 клубта даими нигездә 560 тан артык берләшмәдә 20 меңнән артык кеше шөгыльләнә. 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында»гы федераль закон нигезендә Казан шәһәренең «Яшүсмер» муниципаль бюджет яшьләр сәясәте учреждениесенең төп максатчан аудиториясе булып 14 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшүсмерләр һәм

яшьләр тора. Яшүсмерләрне һәм яшьләрне җәлеп итү максатыннан 2023 елдан яшүсмерләр клублары атнага җиде көн эшләүгә күчте.

Ял итүне оештыру дүрт төп юнәлеш буенча башкарыла:

1. балалар һәм яшьләрнең ялы һәм мәшгульлеге;
2. яшьләр арасында социаль яктан тискәре күренешләрне профилактикалау;
3. патриотик тәрбия бирү;
4. гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру.

2023 елдан башлап «Хобби-бокс» мобиль яшүсмерләр клубы проекты тормышка ашырыла. Ул Казан шәһәренең ерак урнашкан поселокларында – Чабакса, Колсәет, Зур Дербышки, «Якты» территориаль иҗтимагый советы, Карьер, Царицынский Бугор, Самосырово, Привольный поселокларында яшәүче балалар һәм яшьләр белән эшчәнлек алып бара, шулай ук җәйге чорда Казан шәһәренең барлык территориясендә «Ишегалдыңдагы клуб» һәм «Притяжение» кебек проектларда 10 000 нән артык кеше катнаша. Казан шәһәренең «Яшүсмер» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесенең гаилә белән эшләвендә төп компонент булып «Бергә» проекты – «Әти-әни+ бала» форматындагы бушлай осталык дәресләре уздыру тора. Алар гаиләнең уртак ялын оештырырга, шулай ук балаларны һәм яшүсмерләрне системалы дәресләргә җәлеп итәргә мөмкинлек бирә. Проект чараларында барлыгы 2,5 меңнән артык кеше катнашты.

2018-2025 елларда Казанның 35 яшүсмерләр клубы ремонтланды, шул исәптән «Яшьләр өчен төбәк» федераль программасы кысаларында «Вертолет» яшьләр үзәге ремонтланды. Яшүсмерләр клублары эшләү тарихында беренче мәртәбә Казанда «Яратам» яшьләр (яшүсмерләр) клубы проектланды һәм төзелде, бу яшьләр өчен ял итү эшчәнлеге диапазонын тагын да киңәйтте. Мәсәлән, беренче мәртәбә Казан яшьләренә үз чараларын ачык террасада уздыру мөмкинлеге бирелде.

1 нче ярдәмче программаның нәтиҗәлелеген бәяләүнең төп критерийлары булып сыйфат һәм сан күрсәткечләре тора, аларны исәпләгәндә 7 дән 17 яшькә кадәрге балаларның гомуми саны исәпкә алына. Статистик мәгълүматларга караганда, бу күрсәткеч 2024 елның 1 гыйнварына Казан шәһәре буенча 186 213 кеше тәшкил иткән.

Казан шәһәренең «Доверие» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе базасында балаларга һәм яшьләргә психологик ярдәм күрсәтү эше дәвам итә. 2025 елда әлеге учреждение психологлар һәм социаль педагоглар

тарафыннан 20 меңгә якын консультация хезмәте күрсәтте, шул исәптән 11 меңнән артыгы – ышаныч телефоны аша.

Казан шәһәре «Доверие» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе балигъ булмаган хокук бозучылар белән эшләүдә үзара килешүгә һәм зыянны каплауга йөз тоткан гадел хөкем программасы белгечләрен эшчәнлеккә җәлеп итә. Әлеге эш ике юнәлеш буенча алып барыла: мәктәптә килештерү хезмәтләрен оештыру һәм Казан шәһәренең район судлары белән хезмәттәшлектә (балигъ булмаганнар эшләре буенча район комиссияләре һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләр белән хезмәттәшлектә) балигъ булмаган хокук бозучылар белән эшләү.

Казан шәһәре «Доверие» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесенең 18 филиалы:

- психологтан шәхси консультацияләр, психологтан гаилә консультацияләре, һөнәр буенча үзбилгеләнеш турында консультацияләр бирәләр, гаиләдәге низаглар буенча медиацияләр үткәрәләр;

- психологик диагностика, тернәкләндерү медиациясе, суд өчен психологик бәяләмә әзерләү, балалар өчен шәхси дәресләр, яшүсмерләр һәм яшьләр өчен интерактив дәресләр үткәрәләр;

- студентларның югары уку йортларының профиль факультетларында практика үтүен, гаиләгә ярдәм программасын гамәлгә ашыралар.

Казан шәһәре «Доверие» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе базасында наркоманнар өчен социаль тернәкләндерү программасы гамәлгә ашырыла һәм яшүсмерләргә һәм яшьләргә ярдәм итү буенча ышаныч телефонының өч линиясе эшли.

Казан шәһәре «Доверие» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе белгечләре ел саен меңләгән яшь кешегә катлаулы тормыш хәлләренә җайлашырга һәм сәламәт яшәү рәвеше, дуслык, мәхәббәт һәм гаилә кыйммәтләре кебек дөрес юлны сайларга ярдәм итә. Үзәктә 80 белгеч эшли: психологлар, педагог-психологлар, социаль хезмәткәрләр, яшьләр белән эшләү буенча белгечләр, юристлар. Алар ел саен үз квалификацияләрен күтәрәләр һәм яңа компетенцияләрен үстерәләр. Ел саен индивидуаль, төркем белән, мәгълүмати-агарту, методик, социаль-тернәкләндерү эшчәнлегенә 47 меңнән артык кеше җәлеп ителә. 2023 елдан алып 2025 елга кадәр тагын 7 яңа филиал Казан шәһәре

«Доверие» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе балансына кчерелде һәм аларда ремонт ясалды.

Казан шәһәренең «А.Гайдар исемендәге Казан яшьләр үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет  учреждениесе (алга таба – А.Гайдар исемендәге Казан яшьләр үзәге) Авиатөзелеш районында әлеге юнәлешкә караган иң популяр учреждениеләрнең берсе булып тора. Биредә түгәрәкләр, клублар, яшьләр эше, мәдәният һәм тарих үсеше, мәдәни-массакүләм һәм патриотик чаралар, бәйрәмнәр, ял  һ.б. оештырыла. Үзәктә хореография, вокал, театр, гамәли иҗат, оригиналь жанр, мода, мәктәпкәчә белем бирү, бал-спорт биюләре, шаяннар һәм тапкырлар клубы, йога юнәлешләре буенча студияләр эшли. Сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикле яшьләр өчен студияләр, өлкәннәр өчен яшь әниләр клубы оештырылды. Бүгенге көндә ул – Казан шәһәрендәге меңнән артык кеше шөгыльләнә торган бердәнбер яшьләр үзәге. Яшьләр үзәге базасында 14 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшьләрне үз эченә алган «Һөнәри белем бирү оешмаларында беренче курста укучылар көне», «Платформа» (эшләүче яшьләр өчен), «Язгы тамчы» (Һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен) кебек шәһәр фестивальләре, «Ягымлы яз» татар милли мәдәнияте яшьләр фестивале, шулай ук интеллектуаль уеннар һәм квестлар үткәрелә. А.Гайдар исемендәге Казан яшьләр үзәге коллективлары ел саен шәһәр, республика, бөтенроссия һәм халыкара фестивальләрдә Гран-при лауреатлары һәм ияләре була. А.Гайдар исемендәге Казан яшьләр үзәге студиясенә язылу электрон рәвештә дә, шәхсщн мөрәҗәгать итеп тә башкарыла. Күпчелек студияләрдә балалар һәм яшьләр бюджет нигезендә шөгыльләнә. 2025 елда 1 100 укучының өч йөзе бюджеттан тыш нигездә шөгыльләнә.

Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагында шулай ук Казан шәһәренең «Дуслык» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет  учреждениесе урнашкан. Ул 50 балага исәпләнгән (40 – тәүлек буе яши, 10 – көндез булу бүлеге), адресы: Казан шәһәре, Восстание урамы, 99а йорт. Учреждение 3 тән 18 яшькә кадәрге балалар һәм үсмерләр өчен тернәкләндерү һәм социаль-психологик ярдәм күрсәтә. Алар әлеге үзәктә компетентлы белгечләр: психологлар, медиклар, тәрбиячеләр, социаль педагоглар күзәтүе астында тәүлек әйләнәсе яши. Белгечләр Казан районнарының опека һәм попечительлек органнары юллавы буенча, эчке эшләр органнарының оператив дежур органнары актлары буенча, ата-аналарның яки үсмернең үзенең гаризасы буенча үзәккә килгән тәрбияләнүчеләр белән адаптация, коррекция, психологик-педагогик һәм үсеш эшләрен оештыралар һәм үткәрәләр.

Ведомство карамагындагы учреждениеләрнең шактый зур уңышларына һәм тотрыклы рәвештә яхшы эш дәрәҗәсенә карамастан, әлеге учреждениеләрнең эшләвендә 1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру кысаларында планлы хәл итүне таләп итә торган проблемалар да бар:

- учреждениеләрнең искергән матди-техник базасы аларның нәтиҗәле эшләвен тулысынча тәэмин итәргә мөмкинлек бирми;

- Казан шәһәренең кайбер микрорайоннарында һәм торак массивларында, шулай ук шәһәрнең яңа торак комплексларында яшьләр сәясәте объектларының булмавы;

- яшьләр сәясәте учреждениеләренең электрон рәвештә хезмәт күрсәтү мөмкинлеге булмау (түгәрәкләргә һәм секцияләргә язылу);

- яшьләр сәясәте учреждениеләренең заманча IT-җиһазлар белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителмәве;

- хәзерге вакытта күпчелек курслар түләүле булганлыктан, педагогларның, яшьләр белән эшләү белгечләренең һәм тармактан тыш хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү өчен финанс мөмкинлеге булмау;

- таләпләр нигезендә квалификация күтәрү һәм яңадан әзерләү курсларын даими узучы педагогларның саны җитәрлек булмау.

## III. Гамәлгә ашыру вакытларын күрсәтеп, 1 нче ярдәмче программаның максаты һәм бурычлары

1 нче ярдәмче программаның максаты – яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәренең нәтиҗәле эшләве һәм сыйфатлы үсеше өчен шартлар тудыру.

Күрсәтелгән максатка ирешү өчен түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү мөһим:

- социальләштерү барышында балалар һәм яшүсмерләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча сыйфатлы хезмәтләр күрсәтү өчен шартлар тудыру, сәләтле балаларга, фән олимпиадаларында, иҗади конкурсларда җиңүчеләргә ярдәм итү, үсеп килүче буынның үз-үзен тормышка ашыру өчен мөмкинлекләр тудыру.

- яшьләр сәясәте учреждениеләрен аларның эш нәтиҗәлелеген, шулай ук алар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең төрлелеген һәм сыйфатын арттыруны тәэмин итү максатыннан модернизацияләү

1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

- яшүсмерләр клубларында шөгыльләнүче балалар санын 24 000 кешегә җиткерү;

- Казан шәһәре «Доверие» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе белгечләренең халыкка шәхси ярдәм күрсәтүен база дәрәҗәсендә саклап калу – ел саен 18 960 кеше;

- янгынга каршы куркынычсызлыкны арттыру һәм кешеләрнең яшәү шартларын яхшырту чаралары булдырылган яшьләр сәясәте объектлары санын гомуми саннан 100 процентка кадәр арттыру;

- квалификация күтәрү курсларын узган хезмәткәрләр өлешен хезмәткәрләрнең гомуми санынннан 87% дәрәҗәсендә саклап калу;

- Казан шәһәренең «Яшүсмер» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе яшәү урыны буенча шәһәр микрорайоннарында яшүсмерләр клублары санын 77 объектка кадәр арттыру (база елы белән чагыштырганда 5 объектка арту).

Чаралар исемлеге, бурычлар һәм чаралар киселешендә нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары 1 нче ярдәмче программаның кушымтасында китерелгән.

1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты: 2026-2030 еллар.

## IV. 1 нче ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү

1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 3 589 686,2 мең сум тәшкил итә, шулардан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына – 3 354 186,2 мең сум һәм бюджеттан тыш акчалар хисабына – 235 500,0 мең сум.

| Ел | Акча күләме, мең сум | |
|---|---|---|
| | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | Бюджеттан тыш чаралар |
| 2026 | 591 402,0 | 47 100,0 |
| 2027 | 645 850,1 | 47 100,0 |
| 2028 | 705 644,7 | 47 100,0 |
| 2029 | 705 644,7 | 47 100,0 |
| 2030 | 705 644,7 | 47 100,0 |
| **БАРЛЫГЫ** | **3 354 186,2** | **235 500,0** |

1 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында. Аңа, тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре муниципаль

берәмлеге бюджеты проектын формалаштырганда, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## V. 1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру механизмы

1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруда Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, аның ведомство карамагындагы учреждениеләр катнаша.

1 нче ярдәмче программа гамәлдәге законнар нигезендә төзелә торган муниципаль контрактлар һәм муниципаль биремнәр буенча гамәлгә ашырыла. 1 нче ярдәмче программа чараларын башкаручылар аларны сыйфатлы һәм вакытында үтәү, финанс чараларын максатчан һәм рациональ файдалану өчен җаваплы.

Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты 1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру һәм ахыргы нәтиҗәләргә ирешү өчен җаваплы, квартал саен 1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен (максатчан индикаторларны) программаны гамәлгә ашыруны барлык чоры дәвамында мониторинглый. Ел нәтиҗәләре буенча 1 нче ярдәмче программа чараларын үтәүнең нәтиҗәлелегенә, финанс чараларын тотуга анализ ясала, күрсәткечләр нигезендә 1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре билгеләнә.

## VI. 1 нче ярдәмче программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль заказчы тарафыннан башкарыла. Аны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге 1 нче ярдәмче программа белән расланган максатчан индикаторларга һәм күрсәткечләргә фактта ирешү дәрәҗәсе буларак бәяләнә.

1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның төп социаль-икътисади нәтиҗәсе яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәренең нәтиҗәле эшләве һәм сыйфатлы үсеше өчен шартлар тудыруда һәм балалар һәм яшүсмерләр белән эшләүнең яңа инновацион формаларын ачыклауда чагыла.

Кичектерелгән гамәлнең нәтиҗәлелеге түбәндәгеләрдә чагылачак:

- яшьләрнең ялы һәм иҗаты өлкәсендә нәтиҗәле эш оештыруда;
- яшьләр белән эшләү белән шөгыльләнүче оешмалар эшчәнлеген координацияләүдә;

- шәһәр балаларының һәм яшьләренең социаль, мәдәни, рухи, физик тәрбиясе дәрәҗәсен күтәрүдә һәм аларны үстерүдә;

- яшьләр сәясәте өлкәсендә хезмәтләрнең сыйфатын һәм төрлелеген арттыруда;

- карамактагы учреждениеләрнең матди-техник базасын яхшыртуда;

- яшьләр сәясәте учреждениеләре тарафыннан энергия ресурсларын куллануны киметүдә.

- муниципаль яшьләр сәясәте учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән кергән керемнәр өлешен арттыруда.

1 нче ярдәмче программага
1 номерлы кушымта

**1 нче «Яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәре эшчәнлеген камилләштерү» ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 1 нче ярдәмче программа чараларын финанслау**

| **Төп чаралар исеме** | **Башкаручылар** | **Төп чараларны үтәү вакытлары** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре** | **Индикатор күрсәткечләре** | | | | | | **Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда** | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 | 2030 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 | 2030 |
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **6** | **7** | **8** | **9** | **10** | **11** | **12** | **13** | **14** | **15** |
| **Максат: яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәренең нәтиҗәле эшчәнлеге һәм сыйфатлы үсеше өчен шартлар тудыру** | | | | | | | | | | | | | | |
| **1. Социальләштерү барышында балалар һәм яшүсмерләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча сыйфатлы хезмәтләр күрсәтү өчен шартлар тудыру, сәләтле балаларга, фән олимпиадаларында, иҗади конкурсларда җиңүчеләргә ярдәм итү, үсеп килүче буынның үз-үзен тормышка ашыру өчен мөмкинлекләр тудыру** | | | | | | | | | | | | | | |
| **Төп чара: яшьләр сәясәте учреждениеләре челтәрен үстерү** | | | | | | | | | | | | | | |
| Балаларга һәм яшьләргә аларны адаптацияләү максатыннан консультатив, психологик, юридик, | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, «Доверие» муниципаль бюджет учреждениесе | 2026-2030 еллар | Бюджет акчалары хисабына күрсәтелгән консультатив, психологик, юридик, педагогик, социаль, ял итү хезмәтләре саны, берәмлек | 8200 | 8300 | 8400 | 8500 | 8600 | 8860 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| педагогик, ял итү, социаль хезмәтләр күрсәтү, психологик консультацияләр һәм социаль хезмәтләр күрсәтү, яшьләр арасында социаль тискәре күренешләрне профилактикалау буенча чаралар үткәрү, сәламәт | | | Бюджеттан тыш акчалар хисабына күрсәтелгән консультатив, психологик, юридик, педагогик, социаль, ял итү хезмәтләре саны, берәмлек | 740 | 740 | 740 | 740 | 740 | 740 | Бюджеттан тыш акчалар | Бюджеттан тыш акчалар | Бюджеттан тыш акчалар | Бюджеттан тыш акчалар | Бюджеттан тыш акчалар |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| яшәү рәвешен формалаштыру (тренинглар, лекцияләр, семинарлар) | | | Бюджет акчалары хисабына чараларда катнашкан кешеләр саны, кеше | 18200 | 18200 | 18200 | 18200 | 18200 | 18200 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |
| | | | Бюджеттан тыш акчалар хисабына чараларда катнашкан кешеләр саны, кеше | 760 | 760 | 760 | 760 | 760 | 760 | Бюджеттан тыш акчалар | Бюджеттан тыш акчалар | Бюджеттан тыш акчалар | Бюджеттан тыш акчалар | Бюджеттан тыш акчалар |
| | | | Ышаныч телефоны аша ярдәм алган кешеләр саны | 11400 | 11400 | 11400 | 11400 | 11400 | 11400 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |
| Балалар һәм яшьләр белән кызыксынулар буенча клуб эшен оештыру, | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, «Яшүсмер» муниципаль бюджет | 2026-2030 еллар | Бюджет акчалары хисабына яшүсмерләр клубларында түгәрәкләр саны, берәмлек | 600 | 600 | 610 | 610 | 620 | 620 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |
| | | | Яшүсмерләр клубларында бюджеттан тыш акчалар | 230 | 230 | 240 | 240 | 250 | 250 | Бюджеттан тыш акчалар | Бюджеттан тыш акчалар | Бюджеттан тыш акчалар | Бюджеттан тыш акчалар | Бюджеттан тыш акчалар |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| төркем белән эшләү, яшүсмерләр һәм яшьләр өчен социаль инициативаларны гамәлгә ашыру, балалар өчен үстерү дәресләре үткәрү | учреждениесе | | хисабына түгәрәкләр саны, берәмлек | | | | | | | | | | | |
| | | | Клубларда шөгыльләнүче балалар саны, кеше | 23000 | 23000 | 23500 | 23500 | 24000 | 24000 | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш чаралар |
| | | | Төрле дәрәҗәдәге конкурсларда, фестивальләрдә, смотрларда, күргәзмәләрдә, конференцияләрдә һәм башка чараларда катнашучы тәрбияләнүчеләрнең гомуми саныннан шөгыльләнүче балалар өлеше, % | 70 | 70 | 70 | 70 | 70 | 70 | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш чаралар |
| | | | Техник иҗат программалары кысаларында техник түгәрәкләргә, остаханәләргә, үзәкләргә һәм технопаркка йөрүче балалар һәм яшьләр өлеше, % | 1,2 | 1,4 | 1,6 | 1,6 | 1,8 | 1,8 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |
| | | | Шәһәр һәм район чаралары, шул исәптән | 50 | 55 | 60 | 65 | 70 | 75 | Казан шәһәре МБ | Казан шәһәре МБ | Казан шәһәре МБ | Казан шәһәре МБ | Казан шәһәре МБ |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | профилактик юнәлештәге чаралар саны | | | | | | | бюджеты | бюджеты | бюджеты | бюджеты | бюджеты |
| | | | Талантлы яшьләргә ярдәм итү һәм аларның иҗади, спорт һәм башка сәләтләрен үстерүгә юнәлтелгән турнирлар, фестивальләр һәм башка чаралар саны | 26 | 26 | 26 | 26 | 26 | 26 | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар |
| | | | Яшәү урыны буенча яшьләр (үсмерләр) клубларында эшләүче яшьләр эшләре белгечләре өчен укыту чаралары саны | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар |
| | | | Шәһәр һәм район күргәзмәләре, яшәү урыны буенча яшьләр (үсмерләр) клубларында гамәли иҗат эшләре саны | 800 | 805 | 810 | 815 | 820 | 825 | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар |
| Балалар һәм яшьләр белән кызыксынулар буенча, | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, А.Гай | 2026-2030 еллар | А.Гайдар исемендәге Казан яшьләр үзәгендә бюджет хисабына шөгыльләнүче | 800 | 800 | 800 | 800 | 800 | 800 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| төркем белән эшне оешты ру, үсмер ләр һәм яшьләр өчен социаль башлан гычлар ны гамәлгә ашыру, балалар өчен үстерү шөгыль ләре үткәрү | дар исемен дәге Казан яшьләр үзәге | | балалар саны, кеше | | | | | | | | | | | |
| | | | А.Гайдар исемендәге Казан яшьләр үзәгендә бюджеттан тыш чаралар хисабына шөгыльләнүче балалар саны, кеше | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 | Бюджет тан тыш акчалар | Бюджет тан тыш акчалар | Бюджет тан тыш акчалар | Бюджет тан тыш акчалар | Бюджет тан тыш акчалар |
| | | | Төрле дәрәҗәдәге конкурсларда, фестивальләрдә, смотрларда, күргәзмәләрдә, конференцияләр дә һәм башка чараларда катнашучы шөгыльләнүче ләрнең гомуми саныннан шөгыльләнүче балалар өлеше, % | 90 | 91 | 92 | 93 | 94 | 95 | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар |
| Яшәү урыны белән тәэмин итеп, социаль хезмәт ләр күрсәтү | Балалар һәм яшьләр эшләре комитет ы, девиант тәртипле балалар өчен социаль-тернәклә ндерү | 2026-2030 еллар | Авыр тормыш хәлендә калган балаларның вакытлыча яшәвен оештыру, койка урыны саны | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджетта н тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджетта н тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджетта н тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджетта н тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджетта н тыш чаралар |
| | | | Штат расписаниесе нигезендә кадрлар белән тәэмин ителешнең | 75 | 75 | 75 | 75 | 75 | 75 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | үзәге | | гомуми дәрәҗәсе, % | | | | | | | | | | | |
| Методик куллан малар бастыру ны оештыру чарала рын үткәрү | Балалар һәм яшьләр эшләре комитет ы карама гындагы учрежде ниеләр | 2026-2030 еллар | Яшьләр сәясәте учреждениеләре тарафыннан чыгарган методик кулланмалар саны | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар |
| **2 бурыч. Яшьләр сәясәте учреждениеләрен аларның эш нәтиҗәлелеген, шулай ук алар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең төрлелеген һәм сыйфатын арттыруны тәэмин итү максатыннан модернизацияләү** | | | | | | | | | | | | | | |
| **Төп чара: матди-техник базаны үстерү һәм ныгыту** | | | | | | | | | | | | | | |
| Яшьләр сәясәте муници паль учрежде ниеләре нең янгынга каршы куркыны чсызлы гын тәэмин итү | Балалар һәм яшьләр эшләре комите ты карама гындагы учрежде ниеләр | 2026-2030 еллар | Янгынга каршы куркынычсыз лыкны арттыру һәм клүчеләр өчен шартларны яхшырту чараларын тәэмин иткән яшьләр сәясәте объектлары өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш чаралар |
| Учрежде ниеләр хезмәткә рләре нең квалифи кация күтәрү һәм яңадан әзерләү курслар ы узуы | Балалар һәм яшьләр эшләре комите ты карама гындагы учрежде ниеләр | 2026-2030 еллар | Яшьләр сәясәте учреждениеләре нең квалификация күтәрү һәм яңадан әзерләү курсларын узган хезмәткәрләре өлеше, % | 9,5 | 9,5 | 9,5 | 9,5 | 9,5 | 9,5 | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджет тан тыш акчалар |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шәһәр микрорайоннарында яшьләр сәясәте объектлары санын арттыру | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы учреждениеләр | 2026-2030 еллар | Яшьләр сәясәте учреждениеләре саны («Яшүсмер» муниципаль бюджет учреждениесенең яшәү урыны буенча яшүсмерләр клублары), берәмлек | 72 | 73 | 74 | 75 | 76 | 77 | Казан шәһәре МБ бюджеты, ТР бюджеты, бюджеттан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, ТР бюджеты, бюджеттан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, ТР бюджеты, бюджеттан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, ТР бюджеты, бюджеттан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, ТР бюджеты, бюджеттан тыш акчалар |
| **Төп чара: яшьләр сәясәте учреждениеләре тарафыннан энергияне сак тотуны һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыруны тәэмин итү** | | | | | | | | | | | | | | |
| Энергияне сак тоту технологияләрен кулланып, энергия ресурсларыннан сак файдалану буенча чаралар үткәрү | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы учреждениеләр | 2026-2030 еллар | Узган ел белән чагыштырганда, ведомство карамагындагы учреждениеләрнең электр энергиясен куллануын киметү, % | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш акчалар |
| | | | Энергияне сак тоту җайланмалары белән җиһазландырылган яшьләр сәясәте объектлары өлеше, % | 85 | 85 | 85 | 85 | 85 | 85 | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш акчалар | Казан шәһәре МБ бюджеты, бюджеттан тыш акчалар |
| **Төп чара: яшьләр сәясәте учреждениеләрендә җәмәгать куркынычсызлыгын һәм аларның террорчылыктан сакланган булуларын тәэмин итү** | | | | | | | | | | | | | | |
| Учреждениеләрдә куркынычсызлык һәм террорчылыкка каршы саклау | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы учрежде | 2026-2030 еллар | Күзәтчелек органнары таләпләре нигезендә учреждениеләрнең куркынычсызлыгы һәм террорчылыктан | 99 | 99 | 99 | 99 | 99 | 99 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| буенча хокук бозуларны бетерү | ниеләр | | сакланышы буенча хокук бозуларны бетерү буенча чаралар үткәреләчәк яшьләр сәясәте объектлары өлеше, % | | | | | | | | | | | |
| **Программа буенча барлыгы**, шул исәптән | | | | | | | | | | **638 502,0** | **692 950,1** | **752 744,7** | **752 744,7** | **752 744,7** |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты хисабына, шул исәптән:<br>- яшьләр сәясәте учреждениеләре объектларының террорчылыктан сакланышын тәэмин итү эшләрен оештыру һәм уздыру | | | | | | | | | | 350,0 | 350,0 | 350,0 | 350,0 | 350,0 |
| - муниципаль йөкләмә кысаларында яшьләр сәясәте учреждениеләренең агымдагы эшчәнлеген тәэмин итү | | | | | | | | | | 589 824,0 | 644 272,1 | 704 066,7 | 704 066,7 | 704 066,7 |
| - муниципаль милекне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү, максатчан субсидия кысаларында күзәтчелек органнары күрсәтмәләрен үтәү | | | | | | | | | | 1 100,0 | 1 100,0 | 1 100,0 | 1 100,0 | 1 100,0 |
| - яшьләр сәясәте учреждениеләре объектларында энергияне сак тотуга һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | 128,0 | 128,0 | 128,0 | 128,0 | 128,0 |
| бюджеттан тыш акчалар хисабына | | | | | | | | | | 47 100,0 | 47 100,0 | 47 100,0 | 47 100,0 | 47 100,0 |

Файдаланылган кыскартулар исемлеге:

- Казан шәһәре МБ бюджеты – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты;
- ТР бюджеты – Татарстан Республикасы бюджеты;
- Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты – Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты;
- Мәгариф идарәсе – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе;
- Физик культура һәм спорт комитеты – Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты;

- «Доверие» муниципаль бюджет учреждениесе – «“Доверие” балалар һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе;

- «Яшүсмер» муниципаль бюджет учреждениесе – «Яшүсмер» яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары берләшмәсе» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе;

- А.Гайдар исемендәге Казан яшьләр үзәге – «А.Гайдар исемендәге Казан яшьләр үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе;

- девиант тәртипле балалар өчен социаль-тернәкләндерү үзәге

Муниципаль программага
4 номерлы кушымта

**2 нче «Балалар һәм яшьләр өчен чаралар оештыру һәм үткәрү» ярдәмче программасы**

## I. Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның атамасы | Балалар һәм яшьләр өчен чаралар оештыру һәм үткәрү (алга таба – 2 нче ярдәмче программа) |
| Муниципаль заказ бирүче | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты (алга таба – Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты) |
| 2 нче ярдәмче программаны төп эшләүче | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты |
| 2 нче ярдәмче программаны башкаручы | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы бюджет учреждениеләре, Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе |
| 2 нче ярдәмче программаның максаты | Яшьләргә эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү, шулай ук шәһәр тормышында аларның ролен күтәрү өчен шартларны камилләштерү |
| 2 нче ярдәмче программаның бурычы | Балаларның һәм яшьләрнең иҗади, интеллектуаль һәм социаль ихтыяҗларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, шулай ук аларның үзлегеннән белем алуына ярдәм итә торган мотивация системасы булдыру |
| 2 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру | 2026-2030 еллар |

<table>
<tr><td>вакытлары</td><td></td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td><td>2 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты хисабына 54 915,5 мең сум тәшкил итә.
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th>Акча күләме, мең сум</th></tr>
<tr><th>Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты</th></tr>
<tr><td>2026</td><td>10 983,1</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>10 983,1</td></tr>
<tr><td>2028</td><td>10 983,1</td></tr>
<tr><td>2029</td><td>10 983,1</td></tr>
<tr><td>2030</td><td>10 983,1</td></tr>
<tr><td>БАРЛЫГЫ</td><td>54 915,5</td></tr>
</table>
Иганәчеләр акчасын җәлеп итү мөмкин.<br>
Искәрмә: 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында, аңа, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>2 нче ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын еллар буенча гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм 2 нче ярдәмче программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td><td>2 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру 2030 елда түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>
- уздырылган гомумшәһәр һәм конкурс чаралары санын база чорыннан 5 берәмлеккә арттыру;<br>
- конкурс чараларында катнашучы балалар һәм яшьләр санын база чорыннан 14 процентка арттыру;<br>
- талантлы һәм инициативалы яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар санын база чоры дәрәҗәсендә саклау, 212 кеше;<br>
- Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты ярдәмендә яшьләр оешмаларының гамәлгә ашырылган проектлары санын база чорыннан 10 берәмлеккә арттыру;<br>
- чараларда катнашучы махсус социаль төркем балалары һәм яшьләре санын саклау, 500 кеше.</td></tr>
</table>

## II. 2 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, шул исәптән 2 нче ярдәмче программа ярдәмендә хәл ителә торган проблемалар

2 нче ярдәмче программада балалар һәм яшьләр потенциалын үстерү өлешендә дәүләт яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләре билгеләнгән.

2 нче ярдәмче программаның төп максаты булып яшьләр белән эшләү өлкәсендә Казан шәһәренең озак вакытка исәпләнгән максатчан программаларын гамәлгә ашыру тәҗрибәсе нигезендә яшьләргә эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү өчен шартларны камилләштерү, шулай ук 2030 елга кадәрге чорга шәһәр тормышында аларның ролен күтәрү тора.

Россия яшьләре социумның яңалыкны тиз кабул итүче һәм мобиль өлеше буларак прогрессив реформаларны хуплый һәм аларны тормышка ашыра. Глобаль дөньядагы үзгәрешләргә бәйле яңа таләпләр, илнең социаль-икътисади үсешенең яңа максатлары системалы яңартуны, дәүләт яшьләр сәясәте бурычларын һәм механизмнарын үстерүне таләп итә.

Россия Федерациясенең өстенлекләре гаиләнең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең тәрбияви ролен ныгытуга юнәлтелгән. Яшьләр гражданлык җәмгыятен үстерү буенча актив позициясен тагын да ачыграк күрсәтә; яшьләр тарафыннан иҗтимагый байлыкларны булдыру механизмнары формалаша.

Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты яшьләр иҗтимагый оешмалары (берләшмәләре), хәрәкәтләре һәм бергәлекләре инициативаларына ярдәм итүгә зур игътибар бирә.

Иҗтимагый яшьләр оешмалары эше – яшьләрне социальләштерүнең классик өлкәләрдән иреклелек, үзләрен оештыру һәм үзбилгеләнеш белән шактый аерылып торган өлкәсе. Моннан тыш, яшьләр оешмаларында эшләү, белем бирү, аралашу һәм ял итүне оештыру белән беррәттән, дәүләтнең һәм җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә дә яшьләр мәнфәгатьләрен кайгырта.

Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты Яшь галимнәр һәм белгечләр советы, Казанның иреклеләр эшчәнлеген (волонтерлыкны) үстерү үзәге, Казандагы студентларның хезмәт отрядлары штабы, Чит ил студентлары һәм аспирантлары ассоциациясе, Казан һөнәри белем бирү оешмалары студентлар үзидарәсе советы, Казан шәһәре югары уку йортларының студентлар клублары советы, Казан студентлар эзләү отрядлары берләшмәсе, Яшьләр ирекле халык дружиналары һәм башкалар кебек иҗтимагый оешмаларга ярдәм итә.

Бүген Казан шәһәренең 65 югары һәм урта һөнәри белем бирү учреждениесендә 164 мең студент белем ала, алар арасында халыкара һәм

бөтенроссия конкурсларында җиңүчеләр дә шактый. Күпләр үзләренең иҗат юлын шәһәр дәрәҗәсендәге фестивальләрдә һәм конкурсларда катнашудан башлый. Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты иҗади иҗтимагый берләшмәләр, яшьләр һәм мәдәни үзәкләр катнашында күп кенә шундый чаралар оештыра. Югары уку йортлары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары арасында «Беренче курс студентлары көне» вузара фестивале югары уку йортында иҗат тормышын башлау өчен менә дигән старт булып тора һәм яңа талантлар ачуга ярдәм итә. «Созвездие – Йолдызлык» яшьләр эстрада сәнгате фестивале һәм «Ягымлы яз» татар милли мәдәнияте яшьләр фестивале мәктәп укучыларына, студентларга, яшьләргә мәдәни белем бирүне үстерүгә ярдәм итәргә, эстрада сәнгате өлкәсендә һөнәри үзбилгеләнүгә юл ачарга, педагогик эшчәнлекнең абруен һәм статусын күтәрергә этәргеч булып тора. «Язгы тамчы» һәм «Студентлар язы» фестивальләре, күп еллар дәвамында студентлар коллективларының сәнгать осталыгын күтәрүнең нәтиҗәле ысулы булып, зур иҗат бәйрәменә һәм республика яшьләре тормышында мөһим вакыйгаларның берсенә әверелде.

2023 елда Пермь шәһәрендә «Россия Студентлар язы» Бөтенроссия фестивале узды, анда тулысынча Казан шәһәре студентларыннан торган Татарстан Республикасы делегациясе катнашты. 2024 елда Саратов шәһәрендә Казан студентлары республиканы әлеге фестивальдә лаеклы тәкъдим иттеләр.

Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты үз алдына куйган төп бурычларның берсе – талантлы яшьләргә, шул исәптән яшь белгечләргә һәм Казан предприятиеләре эшчеләренә ярдәм итү һәм аларны үстерү. Һәр эре җитештерү оешмасында диярлек профсоюзның яшьләр звеносы һәм «Предприятиеләр һәм оешмалар яшьләре берлеге» иҗтимагый оешмасының ячейкасы эшли. 2014 елдан әлеге берлек Казан шәһәренең «А.Гайдар исемендәге Казан яшьләр үзәге» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе базасында эшли һәм күп кенә чаралар үткәрә, шул исәптән ел саен үткәрелә торган һәм социаль проектлар конкурсын, команда туплау конкурсын һәм эшләүче яшьләр өчен интеллектуаль этапны берләштергән «Платформа» яшьләр инициативалары проектын гамәлгә ашыра. Казан шәһәренең 11 предприятие һәм оешмасыннан 250 дән артык белгеч үз эшләрендә иң яхшылар дип аталу хокукы өчен гадел көрәштә ярыша, үзләренең белемнәрен һәм күнекмәләрен теориядә генә түгел, ә практикада да күрсәтә.

Шулай ук Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты Казан шәһәрендә массакүләм вакыйгалар оештыра. «Гомумшәһәр чыгарылыш кичәсе» һәм «Соңгы кыңгырау» чаралары шәһәрдәге мәктәпне тәмамлаган 10 меңнән артык

укучыны берләштерә һәм аларны олы тормыш юлына чыгара. Моннан тыш, чара барышында Казан шәһәренең югары уку йортлары укучыларны үз учреждениеләре белән таныштыру максатыннан һөнәри юнәлеш күргәзмәсе үткәрә. Бөтенроссия Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көнен бәйрәм итүгә багышланган «Зур гаилә пикнигы» шәһәр фестивале гаилә кыйммәтләрен ныгытуга, шәһәрдә яшәүчеләрнең ял итү һәм аралашу өчен шартлар тудыруга, шулай ук яшь гаиләләргә һәм гаилә корырга ниятләүчеләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән.

Хәзерге яшьләр тормышында мәгълүмати технологияләрнең мөһим роле турында да онытырга ярамый. Бүген социаль челтәрләр – аралашу ысулы гына түгел, ә мәгълүматны тиз белергә яки таратырга мөмкинлек бирә торган иң популяр яңалыклар каналы да. Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты социаль челтәрләрдә аккаунтларын актив үстерә. Файдалы мәгълүмат һәм сыйфатлы күңел ачу контенты  – «Казан яшьләре» телеграм-каналына 5 меңнән артык кешене, ә «ВКонтакте» сайтындагы «Казанның Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты» төркемендә Интернет челтәрендәге 37 меңнән артык кулланучыны кызыксындырырга мөмкинлек бирде.

Соңгы елларда Россиядә яшьләрнең социаль-икътисади хәле яхшыра бара. Казан яшьләре халыкара, бөтенроссия спорт ярышларында, иҗади конкурсларда һәм олимпиадаларда җиңүчеләр һәм призерлар рәтенә керә.

Шуның белән бергә эчке һәм тышкы факторларның кыйммәтләргә карата, иҗтимагый һәм социаль-икътисади характердагы куркынычларны арттыра торган тискәре йогынтысы үсү тенденциясе дә бар. Яшьләргә деструктив мәгълүмати йогынты ясау проблемалы фактор булып тора, аның нәтиҗәсе, башка илләр тәҗрибәсе күрсәткәнчә, социаль катламнар шартларында яшьләр арасында югары агрессивлык, милли һәм дини түземсезлек, шулай ук җәмгыятьтә социаль киеренкелек булырга мөмкин.

Инновацияләр үсеше белән бәйле рәвештә, яшьләрнең хәзерге җәмгыятьтәге роле арта бара. Яшьләргә карата, бер яктан, мөстәкыйль социаль-демографик төркем буларак, икенче яктан, җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә инновацион потенциалы һәм роле исәпкә алынырга тиешле аерылгысыз өлеше буларак мөнәсәбәт булырга тиеш. Хәзерге социаль үсеш характеры дәүләт эшчәнлегендә яшьләрнең катнашуын укучылар гына түгел, ә тулы хокуклы партнерлар яки лидерлар буларак та кирәкле итә. Шундый караш нигезендә, безнең республикабызның күпмилләтле нигезен исәпкә алып, яшь буынны тәрбияләү һәм үстерү шартларын булдыруны күздә тоткан кыйммәтләр системасын формалаштыруга юнәлтелгән заманча яшьләр сәясәтен булдыру

зарур.

## III. «Гамәлгә ашыру вакытларын күрсәтеп, 2 нче ярдәмче программаның максаты һәм бурычлары

2 нче ярдәмче программаның максаты булып яшьләргә эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү, шулай ук шәһәр тормышында аларның ролен күтәрү өчен шартларны камилләштерү тора.

Максатка ирешү өчен балаларның һәм яшьләрнең иҗади, интеллектуаль һәм социаль ихтыяҗларын тормышка ашыру өчен шартлар тудыру бурычын, шулай ук аларның үзлегеннән белем алуына ярдәм итә торган мотивация системасын хәл итү зарур.

2 нче ярдәмче программа яшьләр сәясәте өлкәсендә эшләүче органнар һәм оешмаларның яшьләрнең үз-үзен тормышка ашыру һәм үз-үзен оештыру өчен шартлар тудырудагы тырышлыкларын берләштерүгә юнәлдерелгән.

2 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты: 2026-2030 еллар.

## IV. 2 нче ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү

2 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты хисабына 54 915,5 мең сум тәшкил итә.

| **Ел** | **Акча күләме, мең сум** |
|---|---|
| | **Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты** |
| 2026 | 10 983,1 |
| 2027 | 10 983,1 |
| 2028 | 10 983,1 |
| 2029 | 10 983,1 |
| 2030 | 10 983,1 |
| **БАРЛЫГЫ** | **54 915,5** |

Иганәчеләр акчасын җәлеп итү мөмкин.

2 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында. Аңа, тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проектын формалаштырганда, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## V. 5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру механизмы

2 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өчен максатчан индикаторларны мониторинглаучы Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты җаваплы.

2 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруда Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының барлык структуралары, Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы учреждениеләр, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре һәм эшчәнлекнең беркетелгән юнәлешләре буенча иҗтимагый яшьләр оешмалары катнаша. Муниципаль милектә булмаган оешмаларны башкаручылар сыйфатында җәлеп итү килешү буенча гамәлгә ашырыла.

2 нче ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру барышында муниципаль заказчы төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә, чараларны тормышка ашыру барышын һәм турыдан-туры башкаручыларның акчаларын нәтиҗәле файдалануны контрольдә тота.

## VI. 2 ярдәмче программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

2 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль заказчы тарафыннан башкарыла. 2 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге 2 нче ярдәмче программа белән расланган максатчан индикаторларга һәм күрсәткечләргә фактта ирешү дәрәҗәсе буларак бәяләнә.

2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыруның төп социаль-икътисади нәтиҗәсе яшьләрне тәрбияләү, үзләрен уңышлы күрсәтү, шулай ук аларны җәмгыятькә кертү шартларын булдырудан, тәэмин итү һәм камилләштерүдән, шәһәр тормышында аларның ролен арттырудан тора.

Кичектерелгән гамәл эффекты түбәндәгеләрдә күренәчәк:

- сәләтле балаларга һәм талантлы яшьләргә дәүләт ярдәме чаралары комплексын камилләштерүдә;
- яшьләрне иҗади, фәнни һәм спорт эшчәнлегенә җәлеп итү өчен нәтиҗәле механизмнар үстерүдә;
- зур шәһәр массакүләм чараларын югары сәнгать-иҗат дәрәҗәсендә уздыруда.
- балалар һәм яшьләр өчен район чараларын үткәрү сыйфатын арттыруда.

2 нче ярдәмче программага
1 номерлы кушымта

**2 нче «Балалар һәм яшьләр өчен чаралар оештыру һәм уздыру» ярдәмче программасы нәтиҗәләрен бәяләү максатлары, бурычлары, индикаторлары һәм 2 нче ярдәмче программа чараларын финанслау**

| Чаралар исемнәре | Башкаручылар | Төп чараларны башкару вакытлары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау, мең сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2025 ел (база елы) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| **Максат: яшьләргә эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү өчен шартларны камилләштерү, шулай ук шәһәр тормышында аларның ролен күтәрү** | | | | | | | | | | | | | | |
| **Бурыч: балаларның һәм яшьләрнең иҗади, интеллектуаль һәм социаль ихтыяҗларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, шулай ук аларның үзлегеннән белем алуына ярдәм итә торган мотивация системасы булдыру** | | | | | | | | | | | | | | |
| **Төп чара: балалар һәм яшьләр өчен чаралар оештыру һәм үткәрү** | | | | | | | | | | | | | | |
| Гомумшәһәр һәм конкурс чараларын оештыру һәм үткәрү («Яшьләр көне» гомумшәһәр бәйрәме, Халыкара | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 2026-2030 еллар | Уздырылган гомумшәһәр һәм конкурс чаралары саны, берәмлек | 54 | 55 | 56 | 57 | 58 | 59 | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| балаларны яклау көне, «Созвездие –Йолдыз лык» яшьләр эстрада сәнгате фестивале, «Студент лар язы» вузара фестивале, «Дөнья энҗесе» ачык студентлар фестивале һ. б.) | | | Конкурс чараларында катнашучы балалар һәм яшьләр саны, кеше | 36000 | 37000 | 38000 | 39000 | 40000 | 41000 | Чаралар ның кален дарь планы нигезен дә Казан шәһәре МБ бюдже ты | Чаралар ның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чаралар ның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чаралар ның кален дарь планы нигезен дә Казан шәһәре МБ бюдже ты | Чаралар ның кален дарь планы нигезен дә Казан шәһәре МБ бюдже ты |
| | | | Чараларда катнашучы махсус социаль төркем балалары һәм яшьләре саны, кеше | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | Чаралар ның кален дарь планы нигезен дә Казан шәһәре МБ бюдже ты | Чаралар ның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чаралар ның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чаралар ның кален дарь планы нигезен дә Казан шәһәре МБ бюдже ты | Чаралар ның кален дарь планы нигезен дә Казан шәһәре МБ бюдже ты |
| **Төп чара: талантлы һәм инициативалы яшьләргә булышлык итү** | | | | | | | | | | | | | | |
| Талантлы һәм инициатива лы яшьләргә ярдәм («Казан яшьләре осталары» һөнәри осталык конкурсы, А.Е.Арбузов | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 2026-2030 еллар | Талантлы һәм инициатива лы яшьләргә ярдәм итү йөзеннән уздырылган чаралар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | Чаралар ның кален дарь планы нигезен дә Казан шәһәре МБ бюдже | Чараларн ың календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чараларн ың календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чаралар ның календар ь планы нигезенд ә Казан шәһәре МБ бюджет ы | Чаралар ның календар ь планы нигезенд ә Казан шәһәре МБ бюджет ы |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| исемендәге премия, Е.К.Завойский исемендәге премия, Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясен алуга конкурс һ. б.) | | | | | | | | | | ты | | | | |
| | | | Талантлы һәм инициативалы яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны, кеше | 212 | 212 | 212 | 212 | 212 | 212 | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты |
| | | | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты ярдәме белән яшьләр оешмалары тарафыннан гамәлгә ашырылган проектлар саны, берәмлек | 70 | 70 | 70 | 75 | 75 | 80 | | | | | |
| **Төп чара: балалар һәм яшьләр өчен район күләмендә чаралар үткәрү** | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Балалар һәм яшьләр өчен район чаралары үткәрү (район администрацияләре чаралары: “Созвездие – Йолдызлык” эстрада сәнгате фестивале, ишегалды спорты төрләре буенча чемпионат) | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, районнар администрацияләре | 2026-2030 еллар | Казан шәһәре районнарында үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ әмлеге бюджеты | Чараларның календарь планы нигезендә Казан шәһәре МБ бюджеты |
| **Ярдәмче программа буенча барлыгы**, шул исәптән | | | | | | | | | | **10 983,1** | **10 983,1** | **10 983,1** | **10 983,1** | **10 983,1** |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына | | | | | | | | | | 10 983,1 | 10 983,1 | 10 983,1 | 10 983,1 | 10 983,1 |
| - балалар һәм яшьләр өчен чаралар оештыру һәм үткәрү | | | | | | | | | | 8 478,1 | 8 478,1 | 8 478,1 | 8 478,1 | 8 478,1 |
| - талантлы яшьләргә фәннең төрле тармаклары буенча шәһәр премияләре | | | | | | | | | | 2 365,0 | 2 365,0 | 2 365,0 | 2 365,0 | 2 365,0 |
| - балалар һәм яшьләр өчен район күләмендә чаралар үткәрү, шул исәптән башка кире кайтарылмый торган керемнәр | | | | | | | | | | 140,0 | 140,0 | 140,0 | 140,0 | 140,0 |
| бюджеттан тыш акчалар хисабына | | | | | | | | | | - | - | - | - | - |

Файдаланылган кыскартулар исемлеге:

- Казан шәһәре МБ бюджеты – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты;
- Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты – Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты;
- районнар администрацияләре – Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре.

2 нче ярдәмче программага
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты чаралары исемлеге һәм аларны финанслау күләмнәре***

| № т/б | Чаралар атамасы | Чараларны гамәлгә ашыру вакытлары | Чараларны гамәлгә ашыруга чыгымнар, мең сумнарда | | | | | Чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы | Тәэмин ителгән кеше саны, кеше | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | | 2025 ел (база елы) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| 1 | Гомумшәһәр һәм конкурс чараларын оештыру һәм үткәрү («Яшьләр көне» гомумшәһәр бәйрәме, Халыкара балаларны яклау көне, «Созвездие – Йолдызлык» яшьләр эстрада сәнгате | Ел дәвамында | 8 478,1 | 8 478,1 | 8 478,1 | 8 478,1 | 8 478,1 | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты (алга таба – Балалар һәм яшьләр эшләре | 36000 | 37000 | 38000 | 39000 | 40000 | 41000 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | фестивале, «Студентлар язы» вузара фестивале, «Дөнья энҗесе» ачык студентлар фестивале, «Һөнәре буенча иң яхшысы» исеменә яшьләр арасында һөнәри осталык конкурсы һ. б.) | | | | | | | комитеты) | | | | | |
| 2 | Талантлы һәм инициативалы яшьләргә ярдәм (А.Е.Арбузов исемендәге премия, Е.К.Завойский исемендәге премия, Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясен алуга конкурс) | Ел дәвамында | 2 365,0 | 2 365,0 | 2 365,0 | 2 365,0 | 2 365,0 | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 210 | 210 | 210 | 212 | 212 | 212 |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Казан шәһәре Башкарма комитеты районнары администрацияләре чаралары («Созвездие – Йолдызлык» эстрада сәнгате фестивале, ишегалды спорты төрләре буенча чемпионат һ. б.) | Ел дәвамында | 140,0 | 140,0 | 140,0 | 140,0 | 140,0 | Казан шәһәре Башкарма комитеты районнары администрацияләре | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 |
| **БАРЛЫГЫ** | | | **10 983,1** | **10 983,1** | **10 983,1** | **10 983,1** | **10 983,1** | **-** | | | | | | |

*Ел дәвамында чараларның исемнәренә төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

Муниципаль программага
5 номерлы кушымта

**3 нче «Балалар һәм яшьләргә гражданлык-патриотик тәрбия бирү» ярдәмче программасы**

## I. Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программа атамасы | Балалар һәм яшьләргә гражданлык-патриотик тәрбия бирү (алга таба – 3 нче ярдәмче программа) |
| Муниципаль заказ бирүче | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты (алга таба – Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты) |
| 3 нче ярдәмче программаны төп эшләүче | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты |
| 3 нче ярдәмче программаны башкаручы | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы бюджет учреждениеләре |
| 3 нче ярдәмче программаның максаты | Патриотик тәрбия бирү һәм иреклеләр эшчәнлеге системасын үстерү һәм камилләштерү |
| 3 нче ярдәмче программаның бурычы | Гамәлдәге шартлар кысаларында динамик үзгәреп торучы вазгыятьне исәпкә алып, актив гражданлык позициясен булдыру |
| 3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакытлары | 2026 – 2030 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, | 3 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты хисабына 4 800,0 мең сум тәшкил итә. |

| Ел | Акча күләме, мең сум |
|---|---|

<table>
<tr>
<td>3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>
<table>
<tr><th></th><th>Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты</th></tr>
<tr><td>2026</td><td>960,0</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>960,0</td></tr>
<tr><td>2028</td><td>960,0</td></tr>
<tr><td>2029</td><td>960,0</td></tr>
<tr><td>2030</td><td>960,0</td></tr>
<tr><td>БАРЛЫГЫ</td><td>4 800,0</td></tr>
</table>
Иганәчеләр акчасын җәлеп итү мөмкин.<br>
Искәрмә: 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында. Аңа, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш
</td>
</tr>
<tr>
<td>3 нче ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре һәм 3 нче ярдәмче программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td>
<td>3 нче ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру 2030 елга түбәндәгеләргә түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>
- патриотик юнәлештәге чараларда катнашучылар санын база чорыннан 9 процентка арттыру;<br>
- патриотик юнәлештәге чаралар санын база елы дәрәҗәсендә калдыру, 27 чара;<br>
- ирекледәр эшчәнлеге буенча үткәрелгән чаралар санын база чорындагыдан 2 берәмлеккә арттыру;<br>
- ирекледәр эшчәнлеге үзәгендә катнашучылар санын база чорындагыдан 6000 кешегә арттыру</td>
</tr>
</table>

## II. 3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, шул исәптән 3 нче ярдәмче программа ярдәмендә хәл ителә торган проблемалар

3 нче ярдәмче программа «Яшьләр һәм балалар» федераль проекты нигезендә эшләнде һәм, динамик рәвештә үзгәрүче вазгыятьне, яшь үзенчәлекләрен һәм иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр), мәгариф учреждениеләре һәм хезмәт коллективлары белән актив хезмәттәшлек итү кирәклеген исәпкә алып, актив гражданлык позициясен формалаштыруга юнәлдерелгән.

Патриотик тәрбия – гражданнарда патриотик аң, Ватанына тугрылык хисе, тыныч тормышта һәм сугыш вакытында Ватан мәнфәгатьләрен яклау буенча конституциячел бурычларны уңышлы үтәргә әзерлек һәм мөмкинлек формалаштыру буенча хакимият органнарының һәм иҗтимагый оешмаларның (берләшмәләрнең) системалы һәм максатчан эшчәнлеге.

Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты тарафыннан патриотик тәрбия эше биш юнәлештә алып барыла: югары һәм һөнәри уку йортлары белән эш, ведомство карамагындагы учреждениеләрдә эш, яшьләрнең патриотик берләшмәләре, башка профильдәге яшьләр оешмалары белән эш, шулай ук Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының традицион планлы патриотик чараларын үткәрү.

Патриотизм формалаштыру системасының мөһим элементы – яшьләр белән эшләүнең төрле юнәлешләре, формалары һәм алымнары: хәрби-спорт уеннары үткәрү, Бөек Ватан сугышы һәм локаль конфликтлар ветераннары белән очрашулар, сафта йөрү һәм җыр смотр-конкурслары һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары өчен ел саен үткәрелә торган активлар мәктәпләре уздыру.

Ел саен Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты партнер оешмалар белән берлектә елына йөздән артык чара үткәрә. Аларның төп максаты – яшьләрнең иҗади потенциалын, сәламәт яшәү рәвешен һәм актив гражданлык позициясен үстерү, шулай ук яшь буынны экстремистик характердагы оешмаларга җәлеп итүне кисәтү һәм террорчылык идеологиясенә каршы тору.

Яшьләргә патриотик тәрбия бирү эшчәнлегендә Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы муниципаль бюджет учреждениеләре мөһим роль уйный. Алар Казан Кремлендәге Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы, «Татарстан Республикасы Диңгез җыелышы» иҗтимагый оешмасы, «Сугышчан ахирәтләр» сугыш ветераннары хатын-кыз фронтовиклар клубы, «“Патриот” республика яшьләргә патриотик-спорт һәм хәрби хезмәткә чакырылуга кадәр әзерлек үзәге» автоном учреждениесе белән тыгыз хезмәттәшлек алып баралар.

Казан шәһәренең «Яшүсмер» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе өчен беренче чираттагы бурычларның берсе булып яшүсмерләргә һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә, үз шәһәре, республикасы, илебез өчен горурлык хисе формалаштыруга юнәлдерелгән программаларны, проектларны һәм чараларны гамәлгә ашыру тора.

Клубларда тәрбияләнүчеләр сәнгать-эстетик, спорт, техник, хәрби-патриотик юнәлештәге түгәрәкләрдә һәм секцияләрдә шөгыльләнәләр, мәдәни-массакүләм һәм спорт чараларын үткәрүдә катнашалар. Казан шәһәренең «Яшүсмер» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе түгәрәкләрендә

һәм секцияләрендә хисап датасына «Батыр» картасы буенча 108 бала бушлай шөгыльләнүен билгеләп үтәргә кирәк.

«Алга» яшьләр-яшүсмерләр клубында патриотик үзәк булдырылды. Үзәкнең максаты – Россиянең яшь гражданины шәхесенең патриотик, физик, интеллектуаль һәм рухи үсеше өчен шартлар тудыру, шулай ук үз Ватанының чын патриотын тәрбияләү һәм анда лидерлык сыйфатлары формалаштыру. Үзәктә төрле архив фотоматериаллары һәм сугыш белән бәйле экспонатлар урнаштырылган Бөек Ватан сугышы музее эшли. Хәзерге вакытта музей базасында «Җиңү волонтерлары» шәһәр штабы эшли.

2024 елның мартында «Алга» клубында КИР «Хронос» белән берлектә «Z.O.V.» квесты узды. Анда егетләр хәрби-физик әзерлектә үз көчләрен сынадылар. Шулай ук «Алга» яшьләр-яшүсмерләр клубында пилотсыз очу аппаратлары җибәрү буенча осталык дәресләре узды.

2024 елның октябреннән «Заря» торак комплексы белән берлектә «Тарихи зарядка» проекты старт алды. Аның максаты – Россия тарихын тирәнтен өйрәнү. Проект кысаларында Казан шәһәре музейларына экскурсияләр, шулай ук тарихи грамоталылыкны арттыруга һәм үткәннәргә хөрмәт белән карау формалаштыруга юнәлдерелгән квиз-уеннар үткәрелә.

А.Гайдар исемендәге Казан яшьләр үзәгендә даими рәвештә түбәндәге патриотик чаралар үткәрелә:

- ел дәвамында яшьләр үзәгендә тәрбияләнүчеләр катнашында концертлар;
- яшьләр үзәгендә тәрбияләнүчеләрдән ачык дәресләр;
- Бөек Ватан сугышына багышланган «Квиз-Лимонад» интеллектуаль-күңел ачу уены;
- «Казанга курс. Ватан батырлары» квест-экскурсиясе;
- «Эзләү фронты» эзләү системасының бөтенроссия мәктәпләрендә лекцияләр уку.

2024 елда «Сугыш шигырьләрдә» әдәби видеопроектын төшерү башланды. Анда проектта катнашучылар Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын яктыртучы шагыйрьләрнең 80 шигырен укый. Проектны социаль челтәрләрдә бастыру 2025 елның 23 февралендә башланды һәм ел дәвамында дәвам итәчәк.

Яшьләр үзәгенең «Язгы тамчы», «Беренче курста укучылар көне», «Ягымлы яз» фестивальләре быел Ватанны саклаучылар елына һәм Җиңүнең 80 еллыгына багышлана.

Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты тарафыннан балаларның патриотик хәрәкәтенә аерым игътибар бирелә.

Мәктәпләрдә һәм яшүсмерләр берләшмәләрендә сугышчан хәрәкәтләр ветераннары белән очрашулар үткәрелә, балаларның укыту-хәрби җыеннарында, «Аҗаган» хәрби-патриотик уенында, сафта йөрү һәм җыр смотрларында катнашуы оештырыла.

Ел саен балалар һәм яшьләр арасында хәрби-гамәли спорт төрләре буенча «Җиңүгә тигезләнү» спартакиадасы үткәрелә. 2024 елда анда Казаннан 300 дән артык бала һәм яшүсмер, шулай ук студент яшьләр катнашты.

Хәрби-гражданлык хезмәтенең әһәмиятле булуына игътибар җәлеп итү, югары хәрби уку йортларына керү идеясен популярлаштыру максатыннан 7 урта һөнәри белем бирү оешмасы базасында 11 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар өчен яшь армия отрядлары эшли. Казанның яшь армиясе хәрби тематика һәм Ватан тарихы белән кызыксынучы 3 500 гә якын баланы берләштерә.

Ел саен Казанның мәктәп укучылары һәм балалар-яшүсмерләр берләшмәләре Җиңү паркындагы Мәңгелек ут янында Хәтер вахтасын ача. Бу акциядә катнашучыларның үзләре өчен дә, Казан халкы өчен дә чын мәгънәсендә әһәмиятле вакыйга.

Россия көнендә шәһәрнең төп сәхнәсендә традиция буенча «Без – Россия гражданнары» акциясе кысаларында укуда яисә социаль актив эшчәнлектә уңышка ирешкәннәргә тантаналы рәвештә паспортлар тапшыру оештырыла. Болар барысы да горурлык һәм үзеңне илнең, республиканың һәм шәһәрнең бер өлеше итеп аңлау хисе уята.

2024 елда Россия көне алдыннан «Казан» гаилә үзәге каршында Россиянең иң зур флагы җәелдерелде. Аның зурлыгы 3 750 квадрат метр, ә яклары 50 һәм 75 метр тәшкил иткән. Акциядә Казанның 500 дән артык кешесе катнашты.

Яшьләргә гражданлык мөнәсәбәтләрен уята торган инициативалар күрсәтү өчен мәйданчык бирү бик мөһим.

Бүгенге көндә Казанда гражданлык-патриотик юнәлештәге 900 дән артык иҗтимагый берләшмә һәм оешма исәпләнә. Алар арасында эзләнү һәм хокук саклау отрядлары, иреклеләр хәрәкәтләре, хәрби-патриотик клублар һәм башкалар бар, аларда меңнән артык яшь кеше катнаша.

2024 елда истә калырлык вакыйгаларның берсе яулап алынган НАТО хәрби техникасы күргәзмәсе булды. Бу вакытта Казан, хәрби техника белән кызыксынучы кешеләрне җыеп, игътибар үзәгенә әверелде. Күргәзмәдә, Украинага хәрби ярдәм буларак НАТО илләре китергән коралларның төп үрнәкләрен дә кертеп, 14 берәмлек техника урнаштырылган иде. Иң көтелгән һәм популяр экспонат 66 тоннадан артык авырлыктагы Abrams танкы булды. Күргәзмә өлкәннәрдә генә түгел, яшьләрдә дә зур кызыксыну уятты. 5 көн эчендә

бу күргәзмәгә Татарстан Республикасының 140 меңнән артык кешесе килде, алар арасында 7 000 нән артык мәктәп укучысы һәм студент бар иде. Чара дәвамында Җиңү волонтерларының Казан бүлеге тарафыннан «Җиңү хаты» бөтенроссия акциясе оештырылды. Әлеге акция барышында теләгән һәркемгә солдатларга хат язу, рәхмәт белдерү мөмкинлеге бирелде. Барлыгы 300 дән артык хат язылды һәм фронтка җибәрелде.

Яшьләр һәм студентлар «Георгий тасмасы», «Ветеранны котла», «Хәтер бакчасы», «Җиңү вальсы», «Үлемсез полк», «Блокада чорында икмәк» бөтенроссия акцияләре һәм башкалар кебек Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү чараларында актив катнашалар.

2025 елның 19 февралендә, Бөек Ватан сугышында Бөек Җиңүгә 80 көн кала, Казан шәһәрендә 3 меңнән артык битараф булмаган волонтерларны берләштергән Җиңүнең 80 еллыгы волонтерлар корпусы эшли башлады. Корпус волонтерлары ветераннар белән бергә вакыт уздырдылар, туганнарының каберләрен җыештырдылар, компьютер грамоталылыгына өйрәттеләр, социаль-көнкүреш ярдәмнәр күрсәттеләр, шулай ук Ватанны саклаучылар елына багышланган барлык чараларда озатып йөрделәр.

Ел саен эзләү һәм хезмәт отрядлары студентларның ирекле халык дружиналары һәм коткаручылар отрядлары катнашында «Обелискка юл» бөтенроссия акциясе кысаларында шәһәр зиратларындагы истәлекле урыннарны, хәрби каберлекләрне һәм мемориалларны төзекләндерә.

Активистларны кызыксындыру максатыннан ел саен түбәндәге чаралар оештырыла: студентларның ирекле халык дружиналары отрядлары арасында Артем Айдинов исемендәге премияләр алуга конкурс, Казан шәһәре волонтерлары арасында «Ел иреклесе» конкурсы, шулай ук студентларның эзләнү хәрәкәте активистларына һәм хезмәт отрядларына агымдагы чорда эшләү нәтиҗәләре буенча акчалата премияләр һәм грантлар түләү, экспедиция урынына кадәр юлда бару өчен түләү, экипировка белән тәэмин итү кебек ярдәм күрсәтелә.

## III. Гамәлгә ашыру вакытларын күрсәтеп, 3 нче ярдәмче программаның максаты һәм бурычлары

3 нче ярдәмче программаның максаты – патриотик тәрбия һәм иреклеләр эшчәнлеге системасын үстерү һәм камилләштерү.

Максатка ирешү өчен, гамәлдәге шартлар кысаларында динамик рәвештә үзгәрүче вазгыятьне исәпкә алып, актив гражданлык позициясен формалаштыру бурычын хәл итәргә кирәк.

3 нче ярдәмче программа патриотик тәрбия бирүне гамәлгә ашыручы хакимият органнарының һәм иҗтимагый оешмаларның (берләшмәләрнең) яшьләрнең үзләрен күрсәтүләре һәм үзләрен оештырулары өчен шартлар тудырудагы тырышлыкларын берләштерүгә юнәлдерелгән.

3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты: 2026-2030 еллар.

## IV. 3 нче ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү

3 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты хисабына 4 800,0 мең сум тәшкил итә.

| **Ел** | **Акча күләме, мең сум** |
|---|---|
| | **Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты** |
| 2026 | 960,0 |
| 2027 | 960,0 |
| 2028 | 960,0 |
| 2029 | 960,0 |
| 2030 | 960,0 |
| **БАРЛЫГЫ** | **4 800,0** |

Иганәчеләр акчасын җәлеп итү мөмкин.

3 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында. Аңа, тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проектын формалаштырганда, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## V. 3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру механизмы

3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруда Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, аның карамагындагы учреждениеләр катнаша.

3 нче ярдәмче программа гамәлдәге законнар нигезендә төзелә торган муниципаль контрактлар һәм муниципаль биремнәр нигезендә гамәлгә ашырыла. 3 нче ярдәмче программа чараларын башкаручылар аларны сыйфатлы һәм вакытында үтәү, финанс чараларын максатчан һәм рациональ файдалану өчен җаваплы.

Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты 3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру һәм ахыргы нәтиҗәләргә ирешү өчен җаваплы, квартал саен 3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен (максатчан

индикаторларын) программаны гамәлгә ашыруның барлык чоры дәвамында мониторинглый. Ел нәтиҗәләре буенча 3 нче ярдәмче программа чараларын үтәүнең нәтиҗәлелегенә, финанс чараларын тотуга анализ ясала, күрсәткечләр нигезендә 3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре билгеләнә.

## VI. 3 нче ярдәмче программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль заказчы тарафыннан башкарыла. 3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге 3 нче ярдәмче программа белән расланган максатчан индикаторларга һәм күрсәткечләргә фактта ирешү дәрәҗәсе буларак бәяләнә.

3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның төп социаль-икътисади нәтиҗәсе патриотик тәрбия системасын үстерү һәм камилләштерүдә чагыла.

Кичектерелгән гамәлнең нәтиҗәлелеге түбәндәгеләрдә чагылачак:

- патриотик тәрбия өлкәсендә эш алып баручы белгечләр һәм остазлар бергәлеген формалаштыруда;
- балаларга һәм яшьләргә өзлексез спорт-патриотик тәрбия бирү системасын формалаштыруда;
- гражданлык-патриотик тәрбиянең мөһим элементы буларак волонтерлык хәрәкәтен үстерү өчен шартларны яхшыртуда;
- патриотик чаралар турында хәбәрдар булган гражданнар санын арттыруда һәм патриотик тәрбияне мәгълүмати яктан тәэмин итү дәрәҗәсен арттыруда.

3 нче ярдәмче программага
1 номерлы кушымта

**3 нче «Балаларга һәм яшьләргә гражданлык-патриотик тәрбия бирү» ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 3 нче ярдәмче программа чараларын финанслау**

| Төп чаралар исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү вакытлары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2025 ел (база елы) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| **Максат: патриотик тәрбия һәм ирекләләр эшчәнлеге системасын үстерү һәм камилләштерү** | | | | | | | | | | | | | | |
| **Бурыч: гамәлдәге шартлар кысаларында динамик үзгәреп торучы вазгыятьне исәпкә алып, актив гражданлык позициясен булдыру** | | | | | | | | | | | | | | |
| **Төп чара: балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү системасын формалаштыру һәм камилләштерү** | | | | | | | | | | | | | | |
| Патриотик юнәлештәге чаралар үткәрү | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 2026-2030 еллар | Патриотик юнәлештә уздырылган чаралар саны, берәмлек | 27 | 27 | 27 | 27 | 27 | 27 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |
| | | | Патриотик юнәлештәге чараларда катнашучылар саны, | 58000 | 61500 | 62000 | 62000 | 62500 | 63000 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | кеше | | | | | | | | | | | |
| Ирекләләр эшчәнлеге юнәлешендә чаралар үткәрү | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 2026-2030 еллар | Ирекләләр эшчәнлеге юнәлешендә уздырылган чаралар саны, берәмлек | 3 | 3 | 3 | 5 | 5 | 5 | - | - | - | - | - |
| | | | Ирекләләр эшчәнлегендә катнашучылар саны, кеше | 35000 | 36000 | 37000 | 38500 | 39500 | 41000 | - | - | - | - | - |
| Актив яшьләргә һәм патриотик юнәлештәге яшьләр оешмаларына ярдәм итү буенча чаралар | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 2026-2030 еллар | Актив яшьләргә һәм патриотик юнәлештәге яшьләр оешмаларына ярдәм итү буенча чаралар саны, берәмлек | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |
| | | | Актив яшьләргә һәм патриотик юнәлештәге | 58 | 205 | 205 | 205 | 210 | 215 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | яшьләр оешмаларына ярдәм итү буенча чараларда катнашучылар саны, кеше | | | | | | | | | | | |
| **Ярдәмче программа буенча барлыгы**, шул исәптән | | | | | | | | | | **960,0** | **960,0** | **960,0** | **960,0** | **960,0** |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына | | | | | | | | | | 960,0 | 960,0 | 960,0 | 960,0 | 960,0 |

Файдаланылган кыскартулар исемлеге:

- Казан шәһәре МБ бюджеты – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты;
- Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты – Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты.

3 нче ярдәмче программага
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының
Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты чаралары
исемлеге һәм аларны финанслау күләмнәре***

| № т/б | Чаралар атамалары | Чараларны гамәлгә ашыру вакытлары | Чараларны гамәлгә ашыруга чыгымнар, мең сумнарда | | | | | Чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы | Чараларда катнашучылар саны, кеше | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | | 2025 ел (база елы) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| 1 | Патриотик юнәлештәге чаралар үткәрү (Әфганстаннан совет гаскәрләрен чыгару көне, Радиация һәлакәтләре һәм афәтләре нәтиҗәләрен | Ел дәвамында | 720,0 | 720,0 | 720,0 | 720,0 | 720,0 | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 61000 | 61500 | 62000 | 62000 | 62500 | 63000 |

| № т/б | Чаралар атамалары | Чаралларны гамәлгә ашыру вакытлары | Чараларны гамәлгә ашыруга чыгымнар, мең сумнарда | | | | | Чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы | Чараларда катнашучылар саны, кеше | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | | 2025 ел (база елы) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| | бетерүдә катнашучылар һәм мондый һәлакәтләр һәм афәтләр корбаннарын искә алу көне, Хәтер һәм кайгы көне, Җиңү көне, Хәрби диңгез флоты көне һ. б.) | | | | | | | | | | | | | |
| 2 | Актив яшьләргә һәм патриотик юнәлештәге яшьләр | Ел дәвамында | 240,0 | 240,0 | 240,0 | 240,0 | 240,0 | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 200 | 205 | 205 | 205 | 210 | 215 |

| № т/б | Чаралар атамалары | Чараларны гамәлгә ашыру вакытлары | Чараларны гамәлгә ашыруга чыгымнар, мең сумнарда | | | | | Чаралар ны гамәлгә ашыру өчен җаваплы | Чараларда катнашучылар саны, кеше | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | | 2025 ел (база елы) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| | оешмаларына ярдәм итү буенча чаралар (Айдинов исемендәге шәһәр премиясе, эзләү хәрәкәте активистларына ярдәм, эзләү отрядлары проектлары конкурсы һ. б.) | | | | | | | | | | | | | |
| **БАРЛЫГЫ** | | **-** | **960,0** | **960,0** | **960,0** | **960,0** | **960,0** | **-** | | | | | | |

*Ел дәвамында чаралар исемнәренә төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

Муниципаль программага
6 номерлы кушымта

**4 нче «Яшьләр сәясәте өлкәсендә башка мәсьәләләр» ярдәмче программасы**

## I. Ярдәмче программа паспорты

<table>
<tr><td>Ярдәмче программаның атамасы</td><td>Яшьләр сәясәте өлкәсендә башка мәсьәләләр (алга таба – 4 нче ярдәмче программа)</td></tr>
<tr><td>4 нче ярдәмче программаның муниципаль заказ бирүчесе</td><td>Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты (алга таба – Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты)</td></tr>
<tr><td>4 нче ярдәмче программаны төп эшләүче</td><td>Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты</td></tr>
<tr><td>4 нче ярдәмче программаның максаты</td><td>Яшьләр сәясәте өлкәсендә нәтиҗәле идарә итү</td></tr>
<tr><td>4 нче ярдәмче программаның бурычы</td><td>Яшьләр сәясәте өлкәсендә оештыру-методик җитәкчелекне тәэмин итү</td></tr>
<tr><td>4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакытлары һәм этаплары</td><td>2026-2030 еллар</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 4 нче ярдәмче программаны</td><td>4 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме – 76 547,4 мең сум, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты хисабына – 76 547,4 мең сум.<table><tr><th rowspan="2">Ел</th><th>Акча күләме, мең сумнарда</th></tr><tr><th>Казан шәһәре муниципаль</th></tr></table></td></tr>
</table>

<table>
<tr><td>финанслау күләмнәре</td><td>
<table>
<tr><td></td><td>берәмлеге бюджеты</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>15 252,1</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>15 296,6</td></tr>
<tr><td>2028</td><td>15 332,9</td></tr>
<tr><td>2029</td><td>15 332,9</td></tr>
<tr><td>2030</td><td>15 332,9</td></tr>
<tr><td>БАРЛЫГЫ</td><td>76 547,4</td></tr>
</table>
Искәрмә:<br>4 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында. Аңа, тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проектын формалаштырганда, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>4 нче ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын еллар буенча гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм  4 нче ярдәмче программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td><td>4 нче ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- йөкләмәләрне билгеләнгән контроль вакыт аралыгында үтәүне 100 процентка тәэмин итү;<br>- түләү вакыты узган кредит бурычының булмавы – 0 берәмлеккә кадәр;<br>- хезмәт хакын түләү вакыты буенча хокук бозуларның булмавы – 0 берәмлеккә кадәр;<br>- бухгалтерлык исәбен алып бару һәм хисаплылыкны тапшыру буенча хокук бозулар булмау – 0 берәмлеккә кадәр;<br>- билгеләнгән хезмәт хакы фондыннан артту очраклары булмау – 1 берәмлеккә кадәр;<br>- хезмәтләрне сыйфатлы күрсәтү.</td></tr>
</table>

## II.  4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, шул исәптән 4 нче ярдәмче программа хәл итәргә тиешле мәсьәләләр исемлеге

Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының төп эш юнәлешләре:

- яшьләр сәясәте өлкәсендә идарә итү системасын камилләштерү;
- яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләренә оештыру-методик яктан җитәкчелек итү, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өлкәсендә эшләүче

учреждениеләрне саклап калу һәм үстерү, аларның матди-техник базасын яхшырту.

Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының милкен һәм акчаларын формалаштыру чыганагы булып бюджет сметасы нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары тора. Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының финанс-хуҗалык эшчәнлеге расланган бюджет сметасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4 нче ярдәмче программа чараларын үтәүгә Казан шәһәре бюджетыннан бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылышы Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә тикшерелә.

Соңгы елларда Казан шәһәрендәге яшьләр сәясәте шәһәрнең социаль үсешендә өстенлекле юнәлешләрнең берсенә әйләнде. Яшьләр инфраструктурасы камилләштерелә, социаль яктан тискәре күренешләрне профилактикалау, сәләтле яшьләргә ярдәм итү һәм балаларга әхлакый-патриотик тәрбия бирү буенча тотрыклы система формалаша. Казан шәһәрендә яшь буынның активлыгы һәм гражданлык ягыннан җитлеккәнлеге иҗтимагый оешмаларда яшьләр санының артуы белән раслана.

Яшьләр сәясәте белән идарә итү өлкәсендә уңай үзгәрешләр булуга карамастан, федераль дәрәҗәдә норматив-хокукый базаның җитәрлек булмавында проблема бар.

4 нче ярдәмче программаны эшләүгә ихтыяҗ яшьләр тармагындагы уңай үзгәрешләрне саклап калу һәм әлеге проблеманы хәл итү теләге белән аңлатыла.

## III. Гамәлгә ашыру вакытларын күрсәтеп, 4 нче ярдәмче программаның максаты һәм бурычлары

4 нче ярдәмче программаның максаты – яшьләр сәясәте өлкәсендә нәтиҗәле идарә итүне тәэмин итү.

Югарыда күрсәтелгән максатны тормышка ашыру өчен яшьләр сәясәте өлкәсендә оештыру-методик җитәкчелекне тәэмин итү бурычын үтәү кирәк.

4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

- түләү вакыты узган кредит бурычының булмавы – 0 берәмлеккә кадәр;
- хезмәт хакын түләү вакыты буенча хокук бозуларның булмавы – 0 берәмлеккә кадәр;

- бухгалтерлык исәбен алып бару һәм хисаплылыкны тапшыру буенча хокук бозулар булмау – 0 берәмлеккә кадәр;

- йөкләмәләрне билгеләнгән контроль вакыт аралыгында үтәүне 100 процентка тәэмин итү;

- ведомство карамагындагы учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләрдән алынган керем күләмнәренең план күрсәткечләрен 100 процентка үтәү;

- хезмәтләрне сыйфатлы күрсәтү.

4 нче ярдәмче программа чаралары исемлеге, бурычлар һәм чаралар киселешендә нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары 4 нче ярдәмче программаның кушымтасында китерелгән.

4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты: 2026-2030 еллар.

## IV. 4 нче ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

4 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты хисабына 76 547,4 мең сум тәшкил итә.

| **Ел** | **Акча күләме, мең сумнарда** |
|---|---|
| | **Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты** |
| 2026 | 15 252,1 |
| 2027 | 15 296,6 |
| 2028 | 15 332,9 |
| 2029 | 15 332,9 |
| 2030 | 15 332,9 |
| **Барлыгы** | **76 547,4** |

4 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында. Аңа, тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проектын формалаштырганда, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## V. 4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру механизмы

4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өчен максатчан индикаторларны мониторинглаучы Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты җаваплы.

4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруда Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының барлык структуралары, аның карамагындагы учреждениеләр һәм эшчәнлекнең беркетелгән юнәлешләре буенча иҗтимагый яшьләр оешмалары, шулай ук шәһәр территориясендә эш итүче һәм муниципаль яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашучы башка юридик һәм физик затлар катнаша.

4 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру барышында муниципаль заказчы төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә, чараларны тормышка ашыру барышын һәм турыдан-туры башкаручыларның акчаларын нәтиҗәле файдалануны контрольдә тота.

4 нче ярдәмче программа чараларын сыйфатлы итеп башкаруга муниципаль программаны гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелә торган финанс ресурсларын планлаштыруны һәм бүлүне төгәл оештыру, матди һәм финанс ресурсларыннан максатчан һәм рациональ файдалануны контрольдә тоту, шулай ук финанс-хуҗалык эшчәнлеген анализлау өчен материаллар җыю һәм әзерләү ярдәм итәчәк.

## VI. 4 нче ярдәмче программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль заказчы тарафыннан башкарыла. 4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге 4 нче ярдәмче программа белән расланган максатчан индикаторларга һәм күрсәткечләргә фактта ирешү дәрәҗәсе буларак бәяләнә.

4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның төп социаль-икътисади нәтиҗәсе яшьләр сәясәте өлкәсендә идарә итүне камилләштерүдә чагыла.

Кичектерелгән гамәлнең нәтиҗәлелеге түбәндәгеләрдә чагылачак:

- Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты эшчәнлеген финанс һәм кадрлар белән тәэмин итү механизмнарын камилләштерүдә;

- Казан шәһәренең яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлекне оештыру-икътисади һәм эчтәлеге ягыннан камилләштерү, тармак учреждениеләре практикасына яңа методикалар кертү юлы белән оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәле системасын формалаштыруда;

- финанс дисциплинасын ныгытуда.

4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру шулай ук Комитет һәм ведомство карамагындагы учреждениеләр хезмәткәрләренең вазифаи бурычларын сыйфатлы, оператив үтәүгә мотивацияне арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

4 нче ярдәмче программага
кушымта

**4 нче «Яшьләр сәясәте өлкәсендә башка мәсьәләләр» ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 4 нче ярдәмче программа чараларын финанслау**

| Чаралар атамасы | Башка ручы лар | Төп чара ларны гамәл гә ашы ру вакыт лары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторла ры | Индикатор күрсәткечләре | | | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2025 ел (база елы) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| **Максат: яшьләр сәясәте өлкәсендә нәтиҗәле идарә итү** | | | | | | | | | | | | | | |
| **Бурыч: яшьләр сәясәте өлкәсендә оештыру-методик җитәкчелекне тәэмин итү** | | | | | | | | | | | | | | |
| **Төп чара: яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль идарә системасын үстерү** | | | | | | | | | | | | | | |

| **Чаралар атамасы** | **Башкаручылар** | **Төп чараларны гамәлгә ашыру вакытлары** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары** | **Индикатор күрсәткечләре** | | | | | | **Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда** | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **2025 ел (база елы)** | **2026 ел** | **2027 ел** | **2028 ел** | **2029 ел** | **2030 ел** | **2026 ел** | **2027 ел** | **2028 ел** | **2029 ел** | **2030 ел** |
| Яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль хезмәткәрләрнең нәтиҗәле һөнәри эшчәнлеге өчен шартлар тәэмин итү | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 2026-2030 еллар | Билгеләнгән контроль срокларда үтәлгән йөкләмәләр өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |
| Тиешле курсларда муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 2026-2030 еллар | Квалификация күтәрү буенча курслар узган муниципаль хезмәткәрләр өлеше, план күрсәткечләреннән % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты джеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |
| Яшьләр сәясәте | Балалар | 2026- | Законнар | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Казан | Казан | Казан | Казан | Казан |

| Чаралар атамасы | Башкаручылар | Төп чараларны гамәлгә ашыру вакытлары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2025 ел (база елы) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| өлкәсендә муниципаль бюджет акчаларын нәтиҗәле тотуны тәэмин итү | һәм яшьләр эшләре комитеты | 2030 еллар | нигезендә учреждениеләр эшчәнлеген тәэмин итү максатыннан төзелгән килешүләрне һәм муниципаль контрактларны үтәү, % | | | | | | | шәһәре МБ бюджеты | шәһәре МБ бюджеты | шәһәре МБ бюджеты | шәһәре МБ бюджеты | шәһәре МБ бюджеты |
| Түләү вакыты узган кредит бурычларын киметү буенча чаралар үткәрү | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 2026-2030 еллар | Кредит бурычлары булган учреждениеләр саны һәм алардагы түләү вакыты узган кредит | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |

| Чаралар атамасы | Башкаручылар | Төп чараларны гамәлгә ашыру вакытлары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2025 ел (база елы) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| | | | бурычларының суммасы, берәмлекләр | | | | | | | | | | | |
| Ведомство карамагындагы яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләрендә хезмәт хакын вакытында түләүне тәэмин итү | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 2026-2030 еллар | Хезмәт хакын түләү вакыты буенча хокук бозулар ачыкланган учреждениеләр саны, берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |
| Муниципаль учреждениеләрнең расланган тарификацияләре һәм билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 2026-2030 еллар | Хезмәт өчен түләүнең расланган фондын арттыру очраклары ачыкланган | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |

| Чаралар атамасы | Башкаручылар | Төп чараларны гамәлгә ашыру вакытлары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикатор күрсәткечләре | | | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2025 ел (база елы) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| чикләрендә хезмәт хакын түләү | | | учреждениеләр саны, берәмлек | | | | | | | | | | | |
| Казан шәһәре муниципаль яшьләр сәясәте учреждениеләре нең эшмәкәрлекне һәм керем китерә торган башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруын контрольдә тоту | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты | 2026-2030 еллар | Карамактагы учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән кеpемнәр күләменең план күрсәткечләрен үтәү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты | Казан шәһәре МБ бюджеты |
| **Ярдәмче программа буенча барлыгы,** шул исәптән | | | | | | | | | | **15 252,1** | **15 296,6** | **15 332,9** | **15 332,9** | **15 332,9** |
| үзәк аппаратны карап тоту | | | | | | | | | | 14 857,3 | 14 901,8 | 14 938,1 | 14 938,1 | 14 938,1 |

| **Чаралар атамасы** | **Башкаручылар** | **Төп чараларны гамәлгә ашыру вакытлары** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары** | **Индикатор күрсәткечләре** | | | | | | **Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда** | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **2025 ел (база елы)** | **2026 ел** | **2027 ел** | **2028 ел** | **2029 ел** | **2030 ел** | **2026 ел** | **2027 ел** | **2028 ел** | **2029 ел** | **2030 ел** |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| оешмалар милкенә салымны һәм җир салымын түләү | | | | | | | | | | 394,8 | 394,8 | 394,8 | 394,8 | 394,8 |

Файдаланылган кыскартулар исемлеге:

- Казан шәһәре МБ бюджеты – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты;
- Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты – Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты.

Муниципаль программага
7 номерлы кушымта

**5 нче «Балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру» ярдәмче программасы**

## I. Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программа атамасы | Балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру (алга таба – 5 нче ярдәмче программа) |
| 5 нче ярдәмче программаның муниципаль заказ бирүчесе | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты (алга таба – Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты) |
| 5 нче ярдәмче программаны төп эшләүче | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты |
| 5 нче ярдәмче программаны башкаручы | Казан шәһәренең «“Ял” балаларны сәламәтләндерү, ял иттерү, эш белән тәэмин итү шәһәр үзәге” яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе, Казан шәһәренең «Яшүсмер» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе |
| 5 нче ярдәмче программаның максаты | Каникул чорында мәктәп яшендәге балаларны ял белән тәэмин итү |

<table>
<tr><td>5 нче ярдәмче программаның бурычы</td><td>Казан шәһәрендә балаларның ялын оештыру һәм сәламәтләндерү өчен тиешле шартлар тудыру, каникул вакытында аларның мәшгульлеген тәэмин итү, сәламәтләндерү нәтиҗәсен арттыру</td></tr>
<tr><td>5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакытлары һәм этаплары</td><td>2026-2030 еллар</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 5 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td><td>5 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 2 220 717,4 мең сум тәшкил итә (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына – 308 532,4 мең сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1 785 607,5 мең сум һәм 126 577,5 мең сум – бюджеттан тыш чаралар хисабына).
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="3">Акча күләме, мең сум</th></tr>
<tr><th>Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты</th><th>Бюджеттан тыш акчалар</th></tr>
<tr><td>2026</td><td>56 669,2</td><td>564 910,2</td><td>25 315,5</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>60 236,7</td><td>593 562,5</td><td>25 315,5</td></tr>
<tr><td>2028</td><td>63 875,5</td><td>627 134,8</td><td>25 315,5</td></tr>
<tr><td>2029</td><td>63 875,5</td><td>җиткерелгән дә</td><td>25 315,5</td></tr>
<tr><td>2030</td><td>63 875,5</td><td>җиткерелгән дә</td><td>25 315,5</td></tr>
<tr><td>БАРЛЫГЫ</td><td>308 532,4</td><td>1 785 607,5</td><td>126 577,5</td></tr>
</table>
Искәрмә: 5 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында. Аңа, тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проектын формалаштырганда, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>5 нче ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын еллар буенча гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы</td><td>5 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру 2030 елда түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- оештырылган ял формалары белән тәэмин ителгән балалар санын 50 000 кешегә кадәр арттыру;<br>- ял белән тәэмин ителгән сәләтле балалар, фән олимпиадаларында, иҗат конкурсларында җиңүчеләр</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм 5 нче ярдәмче программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | өлешен Казан шәһәрендә әлеге категориягә караган мәктәп яшендәге балаларның гомуми санынннан 37,5 % дәрәҗәсендә саклап калу;<br>- актив ял итү формалары белән тәэмин ителгән балалар өлешен профилактик исәптә торучы балаларның гомуми санынннан 11% дәрәҗәсендә саклап калу;<br>- авыр тормыш хәлендә булган һәм сәламәтләндерелергә тиешле сәламәтләндерү чаралары белән тәэмин ителгән балалар өлешен Казан шәһәрендәге әлеге категориядәге балаларның гомуми санынннан 13% дәрәҗәсендә саклап калу;<br>- белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге лагерьларда ял иткән балаларның өлешен укучыларның гомуми санынннан 15% дәрәҗәсендә саклап калу;<br>- хезмәт һәм ял лагерьларында эш белән тәэмин ителгәннәр өлешен балигъ булмаган гражданнарның гомуми санынннан 1,4% дәрәҗәсендә саклап калу |

## II. 5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, шул исәптән 5 нче ярдәмче программа ярдәмендә хәл ителә торган проблемалар

Казан шәһәре балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру Казан шәһәре яшьләр сәясәтенең мөһим юнәлеше һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының барлык бүлекчәләренең гомуми бурычы булып тора. Җәйге һәм каникул чорында балаларны төрле оешкан ял итү формалары белән тәэмин итү буенча җитди эш алып барыла.

Программа чараларын гамәлгә ашыруда 368 ял оешмасы катнаша, шул исәптән:

- шәһәр янындагы 27 ял оешмасы;
- мәгариф оешмалары тарафыннан оештырылган 170 лагерь;
- 170 хезмәт һәм ял лагере;
- 1 «Галактика балалары» палаткалар лагере.

Ел дәвамында Казанда 48 158 бала һәм яшүсмернең ялы планлаштырыла. Авыр тормыш хәлендә калган балалар – 1 123 кеше, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балалары – якынча 2 500, инвалид һәм сәламәтлеге ягыннан

мөмкинлекләре чикле балалар – 170 кеше ялын оештыруга аерым игътибар бирелә.

Барлык сәламәтләндерү оешмаларында медицина хезмәткәрләренең тәүлек буе кизү торуы тәэмин ителә. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре сәламәтлек саклау идарәсе ярдәмендә барлык шәһәр яны лагерьлары медицина хезмәткәрләре белән тәэмин ителгән; 100 дән артык табиб һәм шәфкать туташы җәлеп ителгән. Белем бирү оешмалары оештырган балалар өчен көндезге лагерьларда белем бирү оешмаларының медицина хезмәткәрләре эшли.

Куркынычсызлык шәхси сак предприятиеләре хезмәткәрләре тарафыннан тәэмин ителә.

Казан шәһәрендә балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча гомуми мониторинг һәм анализ Казан шәһәренең «“Ял” балаларны сәламәтләндерү, ял иттерү, эш белән тәэмин итү шәһәр үзәге” яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан башкарыла.

Ел саен балалар, үсмерләр һәм яшьләрнең социаль хәлен һәм тормыш сыйфатын яхшырту буенча системалы максатчан эш алып барыла.

Кайбер уңай тенденцияләр булуга карамастан, хәзерге вакытта балалар һәм яшьләрнең сәламәтлеген саклау һәм ныгыту мәсьәләләре элеккечә актуаль булып кала. Балалар һәм яшүсмерләрнең психоактив матдәләр куллануы белән бәйле вазгыять борчу тудыра. Шулай ук Казан шәһәрендә ял итүнең агымдагы һәм перспективалы торышының әһәмиятен билгеләүче актуаль проблема булып балалар җинаятьчелеге кала бирә. Бүген балигъ булмаганнар арасында җинаятьчелек төрле вакыт күрсәткечләре (тәүлек вакыты, атна көннәре, ел фасыллары) буенча динамиканың тигез булмавы белән характерлана. Бу исә объектив факторлар белән генә түгел, ә яшүсмерләрнең яшь буенча психологик үзенчәлекләре белән дә аңлатыла. Ел дәвамында җинаятьләрнең иң югары ноктасы каникулларга туры килә, бу балигъ булмаганнарга социаль контрольнең кимүе, хезмәт һәм ял лагерьларының эше туктау, каникул вакытында укучылар белән эшләүнең элек гамәлдә булган системасы юкка чыгу белән бәйле.

Балаларның сәламәтлеге экологик хәлнең начараюы, туклану җитәрлек булмау һәм баланска салынмаган булу, мәгариф оешмаларында, гаиләдә балаларны укыту һәм тәрбияләү шартлары һәм технологиясе, гаиләләрнең икътисади иминлеге кимү һәм җәмгыятьтә социаль киеренкелек белән бәйле стресслар килеп чыгу, начар гадәтләр киң таралу кебек социаль-икътисади, демографик һәм медик-биологик факторларның бер-берсенә тәэсир итүенең интеграль күрсәткече буларак формалаша.

Яшьләрне эшкә урнаштыру, аларның хәзерге җәмгыятьтә социаль җайлашуы проблемасы саклана.

Әлеге күренешләрне профилактикалау өчен ял оешмаларында балаларны лагерьларга җәлеп итү, анда профильле сменалар оештыру буенча планлы һәм максатчан эш алып барыла.

Укучыларның педагогик максатка ярашлы, эмоциональ яктан җәлеп итүчән ялын оештыру, тәэсирләр яңалыгына, хезмәт, танып белү, сәнгать, мәдәният, уен һәм мөмкин булган башка үзбилгеләнеш өлкәләрен үз эченә алган төрле формаларда иҗади яктан үзеңне күрсәтүгә, аралашуга һәм үзешчән эшчәнлеккә булган ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен уңай шартлар тудыру зарур. Шуңа бәйле рәвештә балалар ялы системасын үстерү өлкәсендә бербөтен һәм эзлекле дәүләт сәясәте актуаль булып тора. Аның төп максаты – балаларның ялы һәм аларны сәламәтләндерү өлкәсендә халыкның сыйфатлы хезмәтләрдән канәгать булу дәрәҗәсен арттыру. Шул ук вакытта ял иттерү һәм сәламәтләндерү сыйфаты дигәндә, санитария-гигиена һәм санитария-эпидемиология таләпләрен төгәл үтәп, балаларның иҗади потенциалын үстерүне, аларның сәламәтлеген саклауны һәм ныгытуны, балаларда авыруларны профилактикалауны, аларның физик культура, спорт һәм туризм белән шөгыльләнүен, балаларда сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыруны, аларның уңайлы әйләнә-тирә мохиттә туклану һәм яшәү режимын үтәүләрен тәэмин итүче чаралар җыелмасы аңлашыла. Бу исә бүген күп кенә кертемнәр таләп итә.

## III. Гамәлгә ашыру вакытларын күрсәтеп, 5 нче ярдәмче программаның максаты һәм бурычлары

5 нче ярдәмче программаның максаты – мәктәп яшендәге балаларны каникул чорында ял белән тәэмин итү. Максатка ирешү өчен Казан шәһәрендә балаларның ялын оештыру һәм аларны сәламәтләндерү, каникул вакытында аларның мәшгульлеген тәэмин итү, сәламәтләндерү нәтиҗәлелеген арттыру өчен тиешле шартлар тудыру бурычларын хәл итәргә кирәк.

5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

- балалар һәм яшьләрнең төрле формаларда ялын, аларны сәламәтләндерүне һәм мәшгульлеген, балалар һәм яшьләр туризмы һәм спортын үстерү; сәләтле балаларны, фән олимпиадалары, иҗади конкурслар җиңүчеләрен ачыклау һәм аларга ярдәм итү системасын формалаштыру;
- балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмаларына, волонтерларга ярдәм, ятим

балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга дәүләт ярдәме күрсәтү;

- балалар арасында авыруларны һәм инвалидлыкны профилактикалау; балигъ булмаганнарның күзәтүчесез калуларын һәм хокук бозуларын профилактикалау;

- авыр тормыш хәлендә калган балаларны нәтиҗәле комплекслы социаль яклау һәм җәмгыятькә интеграцияләүне формалаштыру;

- каникул чорында мәктәп яшендәге балаларны ял белән тәэмин итү;

- балаларны һәм яшьләрне, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын каникул чорында ял, сәламәтләндерү чаралары белән тәэмин итү;

- тормыш эшчәнлеге шартларын яхшырту һәм имин булмаган хәлдәге балалар проблемаларын хәл итү;

- каникул чорында балаларны һәм яшьләрне мәшгульлек белән тәэмин итү;

- оештырылган ял формалары белән тәэмин ителгән балалар санын 50 000 кешегә кадәр арттыру;

- балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру, сәламәтләндерү нәтиҗәлелеген арттыру.

5 нче ярдәмче программа чаралары исемлеге, бурычлар һәм чаралар киселешендә нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары 5 нче ярдәмче программаның кушымтасында китерелгән.

5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты: 2026-2030 еллар.

## IV. 5 нче ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү

5 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 2 220 717,4 мең сум тәшкил итә (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына – 308 532,4 мең сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1 785 607,5 мең сум һәм 126 577,5 мең сум – бюджеттан тыш чаралар хисабына).

| Ел | Акча күләме, мең сумнарда | | |
|---|---|---|---|
| | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Бюджеттан тыш чаралар |
| 2025 | 56 669,2 | 564 910,2 | 25 315,5 |
| 2026 | 60 236,7 | 593 562,5 | 25 315,5 |
| 2027 | 63 875,5 | 627 134,8 | 25 315,5 |
| 2028 | 63 875,5 | җиткерелгәндә | 25 315,5 |
| 2029 | 63 875,5 | җиткерелгәндә | 25 315,5 |
| **Барлыгы** | **308 532,4** | **1 785 607,5** | **126 577,5** |

Иганәчеләр акчасын җәлеп итү мөмкин.

5 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында. Аңа, тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проектын формалаштырганда, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## V. 5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру механизмы

5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруда Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, аның ведомство карамагындагы учреждениеләр катнаша.

5 нче ярдәмче программа гамәлдәге законнар нигезендә төзелә торган муниципаль контрактлар һәм муниципаль биремнәр нигезендә гамәлгә ашырыла. 5 нче ярдәмче программа чараларын башкаручылар аларны сыйфатлы һәм вакытында үтәү, финанс чараларын максатчан һәм рациональ файдалану өчен җаваплы.

Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты 5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру һәм ахыргы нәтиҗәләргә ирешү өчен җаваплы, квартал саен 5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен (максатчан индикаторларын) программаны гамәлгә ашыруны барлык чоры дәвамында мониторинглый. Ел нәтиҗәләре буенча 5 нче ярдәмче программа чараларын үтәүнең нәтиҗәлелегенә, финанс чараларын тотуга анализ ясала, күрсәткечләр нигезендә 5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре билгеләнә.

## VI. 5 нче ярдәмче программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль заказчы тарафыннан башкарыла. 5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге 5 нче ярдәмче программа белән расланган максатчан индикаторларга һәм күрсәткечләргә фактта ирешү дәрәҗәсе буларак бәяләнә.

5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның төп социаль-икътисади нәтиҗәсе балалар ялы системасын үстерүдә һәм камилләштерүдә чагыла. Кичектерелгән гамәл эффекты чагылачак:

- балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру, сәламәтләндерү нәтиҗәлелеген арттыруда;
- авыр тормыш хәлендә калган балаларны нәтиҗәле комплекслы социаль яклау һәм җәмгыятькә интеграцияләү формалаштыруда;

- яшьләр өчен эш урыннары булдыру һәм социаль тотрыклылыкны арттыруда;

- балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен шартлар тудыруда.

5 нче ярдәмче программага
кушымта

**5 нче «Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру» ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 5 нче ярдәмче программа чараларын финанслау**

| **Төп чаралар ның атамалары** | **Башка ручы лар** | **Төп чара лар ны баш кару ва кыт лары** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор лары, үлчәү берәмлекләре** | **Индикатор күрсәткечләре** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **2025 ел (база елы)** | **2026 ел** | **2027 ел** | **2028 ел** | **2029 ел** | **2030 ел** |
| **Максат: каникул чорында мәктәп яшендәге балаларны ял белән тәэмин итү** | | | | | | | | | |
| **Бурыч: Казан шәһәрендә балаларның ялын оештыру һәм сәламәтләндерү өчен тиешле шартлар тудыру, каникул вакытында аларның мәшгульлеген тәэмин итү, сәламәтләндерү нәтиҗәсен арттыру** | | | | | | | | | |
| **Төп чара: каникул вакытында балаларның ялын оештыру** | | | | | | | | | |
| Сәләтле балаларны, фән олимпиада ларында, иҗади конкурслар | Балалар һәм яшьләр эшләре комите ты, Мәгари | 2026-2030 еллар | Ял белән тәэмин ителгән сәләтле балалар, фән олимпиадала рында, иҗади конкурсларда | 37,5 | 37,5 | 37,5 | 37,5 | 37,5 | 37,5 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| да җинүчеләр не ачыклау, шулай ук аларга ярдәм итү системасын булдыру | ф идарәсе, Физик культура һәм спорт комитеты | | җинүчеләрнең Казан шәһәрендә әлеге категориягә караган мәктәп яшендәге балаларның гомуми санындагы өлеше, % | | | | | | |
| | | 2026-2030 еллар | Сизелерлек сәламәтләндерү нәтиҗәлелеге дәрәҗәсе, % | 96,0 | 96,0 | 96,0 | 97,0 | 97,0 | 97,0 |
| Балигъ булмаганнар арасында караучысызлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалау | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Мәгариф идарәсе, Физик культура һәм спорт комитеты | 2026-2030 еллар | Профилактик исәптә торучы балаларның гомуми санында актив ял итү формалары белән тәэмин ителгән балалар өлеше, % | 11,0 | 11,0 | 11,0 | 11,0 | 11,0 | 11,0 |
| | | | Сизелерлек сәламәтләндерү нәтиҗәлелеге дәрәҗәсе, % | 85,0 | 85,0 | 85,0 | 86,0 | 86,0 | 86,0 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Авыр тормыш хәлендә калган балаларны нәтиҗәле комплексль социаль яклауны һәм җәмгыятькә интеграцияләүне формалаштыру | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Мәгариф идарәсе, Физик культура һәм спорт комитеты | 2026-2030 еллар | Авыр тормыш хәлендә булган һәм сәламәтләндерелергә тиешле сәламәтләндерү чаралары белән тәэмин ителгән балаларның Казан шәһәрендәге әлеге категориядәге балаларның гомуми санынннан өлеше, % | 13,0 | 13,0 | 13,0 | 13,0 | 13,0 | 13,0 |
| | | | Сизелерлек сәламәтләндерү нәтиҗәлелеге дәрәҗәсе, % | 92,0 | 92,0 | 92,0 | 93,0 | 93,0 | 93,0 |
| Каникул чорында мәктәп яшендәге балаларны ял белән тәэмин итү, % | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Мәгариф идарәсе, Физик культура һәм | 2026-2030 еллар | Белем бирү оешмалары оештырган лагерьларда укучыларның гомуми санынннан көндез ял итә торган балалар өлеше, % | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| | | | Сизелерлек сәламәтләндерү | 70,0 | 70,0 | 70,0 | 70,0 | 70,0 | 70,0 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | спорт комитеты | | нәтиҗәлелеге дәрәҗәсе, % | | | | | | |
| Каникул чорында балаларны һәм яшьләрне мәшгульлек белән тәэмин итү | Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Мәгариф идарәсе, Физик культура һәм спорт комитеты | 2026-2030 еллар | Балигъ булмаган гражданнарның гомуми саныннан хезмәт һәм ял лагерьларында мәшгульлек белән тәэмин ителгән өлеше, % | 1,4 | 1,4 | 1,4 | 1,4 | 1,4 | 1,4 |
| | | | Эшкә урнаштырылган балигъ булмаган гражданнарның гомуми саныннан хезмәт һәм ял лагерьларында мәшгульлек белән тәэмин ителгән өлеше, % | 40,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 |
| 5 нче ярдәмче программаны финанслау, мең сум<br>Программа буенча барлыгы, шул исәптән | | | | **496 467,0** | **646 894,9** | **679 114,7** | **716 325,8** | **89 191,0** | **89 191,0** |
| «Ял» шәһәр үзәге эшчәнлеген тәэмин итү | | | | 47 965,2 | 50 963,0 | 54 301,2 | 57 645,6 | 57 645,6 | 57 645,6 |
| - Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына | | | | 47 965,2 | 50 963,0 | 54 301,2 | 57 645,6 | 57 645,6 | 57 645,6 |
| Балаларның ялын оештыру чаралары,<br>шул исәптән | | | | 423 186,2 | 570 616,4 | 599 498,0 | 633 364,7 | 6 229,9 | 6 229,9 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| - Татарстан Республикасы акчалары хисабына – Татарстан Республикасы бюджетында муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү өчен каралган акчалар хисабына каникул вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итүне финанслауда катнашу чыгымнары | 418 954,3 | 564 910,2 | 593 562,5 | 627 134,8 | җиткерелгәндә | җиткерелгәндә |
| - Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты хисабына – муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларында каникул вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү буенча каралган акчалар хисабына финанслауда катнашу чыгымнары | 4 231,9 | 5 706,2 | 5 935,5 | 6 229,9 | 6 229,9 | 6 229,9 |
| Бюджеттан тыш чаралар | 25 315,5 | 25 315,5 | 25 315,5 | 25 315,5 | 25 315,5 | 25 315,5 |

Файдаланылган кыскартулар исемлеге:

- Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты – Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты;
- Физик культура һәм спорт комитеты – Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты;
- Мәгариф идарәсе – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе.

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 15 гыйнварындагы
28 номерлы карарына
2 номерлы кушымта
(Форма)

**20_____елның ______________________ өчен**
**«2026-2030 елларга Казан шәһәрендә яшьләр сәясәтен үстерү»**
**муниципаль программасын гамәлгә ашыру турында хисап***

| № т/б | Ярдәмче программаның атамасы | Хисап елына программаны финанслауның план күләмнәре, мең сум | | | | Хисап чорында программа буенча бүлеп бирелгән, мең сум | | | | Ел башыннан фактта тотылган акча (башкаручы счетыннан күчерелгән), мең сум | | | | Башкару проценты | | | | Индикатор атамасы, үлчәү берәмлеге | Индикатор күрсәткече | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | шул исәптән | | | барлыгы | шул исәптән | | | барлыгы | шул исәптән | | | барлыгы | шул исәптән | | | | 2025 база елы | агымдагы ел | | | киләсе елга план |
| | | | Казан шәһәре бюджеты | Татарстан Республикасы | бюджеттан тыш чыганаклар | | Казан шәһәре бюджеты | Татарстан Республикасы | бюджеттан тыш чыганаклар | | Казан шәһәре бюджеты | Татарстан Республикасы | бюджеттан тыш чыганаклар | | Казан шәһәре бюджеты | Татарстан Республикасы | бюджеттан тыш чыганаклар | | | план | факт | башкару проценты | |
| 1 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

*Хисап Excel форматында тапшырыла.

________________________________